- *5 баллов выставляется студенту, если допущеныболее 4-5 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 10 ошибок.*

***Вопросы для терминологической работы № 2***

1. Сүз ахырында янәшә килгән ике тартыктан соң сузык аваз өстәлү күренеше.
2. Авазның үзеннән алда килгән авазны охшашландыруы.
3. Сөйләм авазларын яңгыраш үзенчәлеге ягыннан өйрәнү аспекты.
4. Сөйләмнең интонацион-мәгънәви кисәге.
5. Мәгълүм бер фонетик позициядә сузык авазның микъдәри үзгәрүе.
6. Сүз ахырындагы сузык авазның төшеп калу күренеше.
7. Ике сүз арасында бертөрле я охшаш сузык очрашуы нигезендә барлыкка килгән фонетик күренеш.
8. Сөйләмнең фонетик кисәкләре.
9. Авазны мәгънәгә мөнәсәбәттә өйрәнүче, сөйләм авазының функциональ әһәмиятен ачыклаучы фән.
10. Территориаль яктан зур булмаган урында яшәүче халык төркемен хезмәтләндерүче тел формасы.

11. Аваз-фонема-хәреф мөнәсәбәтен өйрәнүче фән тармагы.
12. Информацияне барлыкка китерү, саклау һәм тапшыру өчен кулланыла торган система.
13. Сузык һәм ярымсузыктан ясалган аваз кушылмасы.
14. Янәшә тартыклар арасына сузык аваз өстәлү күренеше.
15. Янәшә торган сузык һәм тартык авазларның артикуляцион яктан бер-берсенә җайлашуы.
16. Фонетика фәнендә сөйләм авазларын өйрәнү аспектлары.
17. Интонацион һәм мәгънәви планда тәмамланган сөйләм кисәге.
18. Телнең яшәү формасы буларак конкрет кешенең индивидуаль теле.
19. Сөйләмнең мәгънәсен аеру өчен җитәрлек булган интонацион компонентлар җыелмасы.
20. Фонетик сүз составындагы басымсыз сүзнең басымлы сүздән алда килү очрагы.
21. Сөйләм берәмлекләрен (иҗек, такт...) әйтү өчен сарыф ителгән вакыт суммасы.
22. Авазларның бер-берсенә тәэсире нигезендә барлыкка килүче закончалыклар.
23. Тартык авазлар системасы.
24. Интонация компонентлары.
25. Беренче тапкыр татар авазларын эксперименталь юл ярдәмендә тикшерүче галим.
26. Сузык авазларның вертикаль хәрәкәте.
27. Фразадагы иң әһәмиятле сүзгә төшә торган басым төре.
28. Авазларның сүздәге урыны, басымга мөнәсәбәте нигезендә барлыкка килгән фонетик закончалыклар.
29. Авазларны язуда дөрес билгеләү кагыйдәләрен һәм кагыйдәләр җыелмасын өйрәнүче фән.
30. Сегмент берәмлекләрне: авазларны һәм башка фонетик кисәкләрне бер-берсенә бәйләп, алардан иҗек, такт, синтагма, фраза оештыру өчен аларга өстәлә-төшә торган фонетик чаралар җыелмасы.
31. Ясалыш урыны буенча берәр генә аваздан торган тартык аваз төркемнәрен атагыз.
32. Сузык авазларны (фонемаларны) берсен икенчесеннән аеруга хезмәт иткән сыйфатларны (билгеләрне) атагыз.
33. Сүз ахырындагы сузык авазның төшеп калу күренеше.
34. Авазларны сөйләмдә дөрес әйтү кагыйдәләрен һәм кагыйдәләр җыелмасын өйрәнүче фән.
35. Тартык авазларны (фонемаларны) бер-береннән аеру өчен хезмәт иткән сыйфатларны (билгеләр) атагыз.

**Критерии оценки (в баллах):**

- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*
- *4 балла выставляется студенту, если допущеныболее 5-6 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущеныболее 10 ошибок.*

**Экзаменационные билеты**

Структура экзаменационного билета:

Экзаменационный билет состоит из 2 теоретических вопросов.

**Примерные вопросы для экзамена**

***ПРИМЕРНЫЙ ПЕРЕЧЕНЬ ВОПРОСОВ К ЭКЗАМЕНУ:***

1. Синонимия күренеше. Лексик синонимга хас билгеләр: аның төрләре.
2. Паронимнар, аларның барлыкка килү юллары; омонимнар, синонимнар белән мөнәсәбәте. Парономазия.
3. Сүзнең күпмәгнәлелеге. Сүзнең төп һәм күчерелмә мәгънәләре. Күчерелмә мәгънә төрләре.

4. Сүз. Сүзгә хас үзенчәлекләр һәм билгеләр. Сүзне өйрәнү юнәлешләре.
5. Антонимия күренеше, аңа хас сыйфатлар һәм аның төрләре. Оксюморон. Антитеза. Катахреза.
6. Тел гыйлеме тармагы буларак лексикология. Аның өйрәнү предметы, берәмлеге, бурычлары, бүлекләре, юнәлешләре.
7. Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составы. Гомумтөрки сүзләр, аларга хас үзенчәлекләр.
8. Сүзнең лексик мәгънәсе. Сүз – предмет – төшенчә. Төшенчә һәм коннотация.
9. Татар телендә гарәп-фарсы алынмалары.
10. Рус теленнән һәм рус теле аша Һинд-Европа теленнән кергән алынмалар.
11. Үзләштерелү дәрәҗәсе күзлегенән алынма сүзләр.
12. Калькалар, аларның төрләре. Пуризм күренеше.
13. Кулланылышы чикләнмәгән лексика. Территориаль яктан чикләнгән лексика, аның төрләре.
14. Социаль яктан кулланылышы чикләнгән лексика, аның төрләре.
15. Искергән сүзләр, аларның төрләре, үзенчәлекләре.
16. Яңа сүзләр: аларның төрләре, үзенчәлекләре.
17. Стилистик битараф һәм аерымланган сүзләр, аларга хас үзенчәлекләр.
18. Татар теленең төп функциональ стильләре, аларга хас үзенчәлекләр.
19. Этимология. Өйрәнү предметы, бурычлары, принциплары. Деэтимологизация, реэтимологизация.
20. Фразеология. Фразеологик әйтелмәләрнең төп билгеләре. Аларның төркемнәре.
21. Ономастика, аның тармаклары, бурычлары.
22. Лексикография турында төшенчә. Сүзлекләрнең төрләре, аларны төзү принциплары.Татар телендә сүзлекләр төзү тарихы.
23. Сүзлекнең лексик мәгънә типлары.
24. Татар телендә омонимия күренеше.
25. Татар лексикасының үсү юллары.

**Образец экзаменационного билета**

БАШКОРТ ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫ
ФИЛОЛОГИЯ ФАКУЛЬТЕТЫ
ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ КАФЕДРАСЫ
ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕ (ЛЕКСИКОЛОГИЯ)

Билет № 2

1. Сүзнең лексик мәгънәсе. Сүз – предмет – төшенчә. Төшенчә һәм коннотация.
2. Татар телендә гарәп-фарсы алынмалары.

Перевод оценки из 100-балльной в четырехбалльную производится следующим образом:
- отлично – от 80 до 110 баллов (включая 10 поощрительных баллов);
- хорошо – от 60 до 79 баллов;
- удовлетворительно – от 45 до 59 баллов;
- неудовлетворительно – менее 45 баллов.

***Критерии оценки (в баллах):***

- ***25-30 баллов*** *выставляется студенту, если студент дал полные, развернутые ответы на все теоретические вопросы билета, продемонстрировал знание функциональных возможностей, терминологии, основных элементов, умение применять теоретические знания при выполнении*

*практических заданий. Студент без затруднений ответил на все дополнительные вопросы. Практическая часть работы выполнена полностью без неточностей и ошибок;*

*- __17-24__ **баллов** выставляется студенту, если студент раскрыл в основном теоретические вопросы, однако допущены неточности в определении основных понятий. При ответе на дополнительные вопросы допущены небольшие неточности. При выполнении практической части работы допущены несущественные ошибки;*

*__- 10-16__ баллов выставляется студенту, если при ответе на теоретические вопросы студентом допущено несколько существенных ошибок в толковании основных понятий. Логика и полнота ответа страдают заметными изъянами. Заметны пробелы в знании основных методов. Теоретические вопросы в целом изложены достаточно, но с пропусками материала. Имеются принципиальные ошибки в логике построения ответа на вопрос. Студент не сделал практическое задание или при выполнении допущены грубые ошибки;*

*- __1-10__ **баллов** выставляется студенту, если ответ на теоретические вопросы свидетельствует о непонимании и крайне неполном знании основных понятий и методов. Обнаруживается отсутствие навыков применения теоретических знаний при выполнении практических заданий. Студент не смог ответить ни на один дополнительный вопрос.*

## ***ПРИМЕРНАЯ ТЕМАТИКА РЕФЕРАТОВ № 2***

1. *Слово как центральная единица языка. Лексическое значение и его типы.*
2. *Лексико-семантическое значение слова.Коннотация.*
3. *Полисемия и ее взаимоотношения с др. явлениями языка (омонимия, синонимия, антонимия)*
4. *Заимствованная лексика в татарском языке.*
5. *Пути развития татарской лексики.*
6. *Фразеология татарского языка.*
7. *Проблема митавации номинаций в татарском языке.*
8. *Ономастика.*
9. *Этимология.*
10. *Основные типы лингвистических словарей.*

Описание методики оценивания:

Рефераты должны быть выполнены методически грамотно и оформлены согласно ГОСТу.

**Критерии оценки (в баллах*):***

*- 4 балла выставляется студенту, если тема раскрыта полностью и если не допущены ошибки;*

*- 3 балла выставляется студенту, если тема раскрыта, но есть некоторые ошибки;*

*- 2 балла выставляется студенту, если тема раскрыта не до конца и в работе допущены ошибки.*

*- 1 балл выставляется студенту, если тема не раскрыта.*

## ***ТЕМАТИКА КУРСОВЫХ РАБОТ***

1. Концепт «дом» в татарской языковой картине мира (на материале пословиц и поговорок)
2. Ономастический анализ стихотворений Ляйсан Кашфи
3. Устаревшая лексика в романе В.Имамова «Казан дастаны»
4. Лингвистические термины в татарском языке
5. Фонетические особенности близкородственных языков (на материале татарского и башкирского языков)
6. Инкорпорация глагола с актантами как основа для образования сложных слов
7. Лексико-семантические и грамматические особенности татарских женских имен

8. Особенности фонетики, грамматики и лексической семантики татарского и казахского языков
9. История и общее развитие Урало-Поволжских народов

*Задания для письменных ответов на вопросы № 2*

1. Лексикологиянең төп бурычларын һәм бүлекләрен атагыз.
2. Сүзгә хас төп сыйфатларны билгеләгез.
3. Лексик-семантик мәгънә типларын һәм аларны аерып чыгару өчен нигез принципларны атагыз.
4. Күпмәгънәлелекнең төрләрен һәм төрчәләрен билгеләгез.
5. Килеп чыгыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составының төп төркемнәрен атагыз.
6. Телдәге стилистик катламнарны билгеләгез.
7. Фразеологиянең төркемнәрен күрсәтегез.
8. Ономастика тармакларын атагыз.

**Критерии оценки (в баллах*):***
- *6 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *4 балла выставляется студенту, если допущены 4 ошибки;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 7 ошибок.*

*Задания для тестового контроля № 3*

1. Әйберне, күренешне индивидуаль исеме белән атамыйча, аңа ишарә ясаучы мәгънә тибы:

а) номинатив мәгънә;
б) абстракт мәгънә;
в) сигнал мәгънә;
г) терминологик мәгънә.

2. Сүзнең атау вазифасы, әйберләргә, күренешләргә атама бирү, исем тагу закончалыкларын өйрәнүче тел белеме тармагы:

а) семасиология;
б) ономасиология;
в) этимология;
г) фразеология.

3. Гомумтел метафораларын билгеләгез.

а) сәгать йөри, тау түбәсе, дәфтәр бите;
б) зәңгәр бәхет, ут толымнары, нечкә билле җил;
в) көлтә койрык, ефәк чәч, көмеш тавыш;
г) торырга почмагым бар, Ак яка керде.

4. Түбәндәге мисаллар арасыннан оксюморонны билгеләгез.

а) дәү – олы, азатлык – бәйсезлек;
б) киреләнү – тискәреләнү, җиһан – дөнья;
в) олы сабый, тере мәет, татлы әрнү;
г) апа –апай, ярашу –ярәшү.

5. «Тере мәет, матур ялган, бәхетсез бәхет, картлык яшьлегем» – сүзләре нинди лингвистик күренешкә карый?

а) синоним;
б) пароним;

в) оксюморон;
г) катахреза.

6. Архаизмнарны билгеләгез.
а) инсан, мантыйкъ, хөррият, ут;
б) лашманчы, чикмән, имана, тархан;
в) полтергейст, чакырунамә, хәбәрдарлык, инвестиция;
г) төнбагыш, бәхетстан, баламишкинлык, антиммәдхия.

7. Теге яки бу халыкның милли гореф-гадәтләрен: йола, йорт, кием, азык, һ.б. яшәеш үзенчәлекләрен чагыштыручы чит ил сүзләре:
а) варваризм;
б) вульгаризм;
в) экзотизм;
г) окказионализм.

8. «Әдәби телдән читтә торган, билгеле бер диалектка гына карамаган сүз һәм әйтелмәләр, грамматик һәм фонетик формалар куллanудан барлыкка килгән сөйләм». – Х. Курбатовның бу билгеләмәсе нинди терминга бирелгән?
а) стильара лексика;
б) фәнни сөйләм;
в) гади сөйләм;
г) шигъри сөйләм.

9.Түбәндәге сүзләр ономастика бүлегенең кайсы тармагы белән бәйле: «Айгизә, Гөлүсә, Шомбай, Дон Кихот…»
а) этнонимика;
б) антропонимика;
в) ойконимика;
г) астронимика.

10. Фразеологизмнар арасыннан грек мифологиясеннән алынганнарын билгеләгез:
а) тимер пәрдә, Сэм агай, сазлыкка тәгәрәү;
б) ызгыш алмасы, канатлы сүзләр, Буридан ишәге, акчаның исе юк;
в) кәкре каенга терәтү, су анасы, Сак белән Сок шикелле;
г) сират күперен үтү, таш ату, Бабил манарасы.

11. Омонимия арасыннан полисемия күренешен күрсәтегез:
а) төш җитте, төш пешерү, йоклаганда төш күрү;
б) компас угы, сатира угы, аткан ук кире кайтмый;
в) күз яшен яшерә, хатын-кызның яшен сорамыйлар, көчле яшен яктысы;
г) миңа таба кил, эзләгән – таба, кибеттән яңа таба алдым.

12. «Бала идәнгә басты», «әни камыр басты» диләр. «Басты» сүзе:
а) омоним;
б) күчерелмә мәгънә;
в) сүзнең бер үк мәгънәсе;
г) синоним.

13. Түбәндәге вариантларда «ихлас» сүзенең антонимын табыгыз
а) ихтыярсыз;
б) игътибарсыз;

в) риялы;
г) ихтыяҗсыз.

14. Татар теленең бары тик үз сүзләреннән генә торган вариантны билгеләгез:
а) халык, мәхәббәт, шәригать, зинһар, бәхет, әдәбият, нәшрият;
б) тормыш, башлык, яшәеш, теләк, үзаллылык;
в) теләк, халык, бәхет, кәбестә, бураэна, эшләпә, башлык, төн;
г) тормыш, машина, болан, билет, гыйшык, туган.

15. «Күз салу», «оекның күзе китү», «күз төшү» дигән сүзтезмәләрдә «күз» сүзе:
а) синоним;
б) күчерелмә мәгънәдә;
в) сүзнең бер үк мәгънәсе;
г) омоним.

16. Түбәндәге вариантларның кайсы «һушсыз» сүзенең синонимик рәтенә тулаем туры килә:
а) һушын югалту, вафат булу, истән язу, дөнья кую, аңсыз булу;
б) аңсыз, һушын югалту, хушлашу, аң җую, хуш ис тарату, истән язу;
в) аңсыз, истән язу, һуш китә, аң җуеп, иссез, һушын югалту;
г) һушсыз, акылсыз, хушлашу, аң җую.

17. Түбәндәге вариантлардан «шифа» сүзенең синонимын табыгыз.
а) шикләнү;
б) дәва;
в) шәфкать;
г) игелек.

18. Тарихи сүзләрне билгеләгез:
а) интернет, брокер, даруханә;
б) чикмән, хан, меньшевиклар;
в) шәкерт, инсан, угыл;
г) аклык, шәфкать, ихтирам.

19. Түбәндәге вариантларның кайсы «шәфкатьле» сүзенең синонимик рәтенә тулаем туры килә?
а) мәрхәмәтле, миһербанлы, аяучан, кешелекле, рәхимле, кече күңелле;
б) мәрхәмәтле, мәхәббәтле, миһербанлы,шифалы, кече күңелле;
в) мәрхәмәтле, файдалы, аяучан, ярдәмчел, уңган, рәхимле, кешелекле;
г) кешелекле, ихлас, иҗтиһатлы, тырыш, күркәм.

20. «Башкала бүген үзенең батыр улларын каршы ала» җөмләсендә күчерелмә мәгънәнең нинди төре күзәтелә?
а) метафора;
б) синекдоха;
в) метонимия;
г) вазифа буенча күчеш.

21. Түбәндәге сүзләр арасыннан кайчандыр бер тамырдан ясалганнарын күрсәтегез:
а) башмак, тормыш, юлбашчы;
б) көньяк, бүген, көнбагыш;
в) колбаса, бастырык, чыгарма;
г) пычак, торак, кисмәк.

22. Ике әйбернең янәшә булуы нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә төре:
а) метафора;
б) метонимия;
в) синекдоха;
г) вазыйфа буенча күчеш.

23. Чит сүзнең морфологик төзелешен һәм мотивировкасын кабул итү нигезендә ясалган сүз:
а) экзотизм;
б) калька;
в) термин;
г) варваризм.

24. Экспрессив бизәктән азат, эмоциональ яктан битараф, бөтен стильләрдә дә кулланыла торган лексика:
а) китап сүзләре;
б) терминнар;
в) көнкүреш сүзләре;
г) стильара лексика.

25. Компонентларның аеруча нык бердәмлеге күзәтелгән фразеологик берәмлек төре:
а) фразеологик бердәмлек;
б) фразеологик ныгыма;
в) фразеологик тезмәләр;
г) фразеологик тәгъбирләр.

### *Задания для тестового контроля №4*

1. Башка мәгънәләргә бәйләнеше булмаган, сүзнең беренчел мәгънәсе буларак кабул ителгән мәгънә тибы:
а) образлы мәгънә;
б) монолексик мәгънә;
в) мотивлашмаган мәгънә;
г) ирекле мәгънә.

2. Оморфларны билгеләгез.
а) алма – алма, алма, бал - бал, белешмә - белешмә;
б) ат (исем) – ат (хайван исеме), төш (сон) – төш (место);
в) яр (исем) – яр (фигыль), тозлар (исем) – тозлар (фигыль);
г) алсу – Алсу, картаю – карт аю.

3. Паронимнарны билгеләгез.
а) ял (ат ялы) – ял (ял итү, бар (иди) – бар (кафе), күк (небо) – күк (синий);
б) ошый – охшый, ярдәмче – ярдәмчел, игелек - изгелек;
в) хөр – ирекле, үпкәләү – рәнҗү, буын - ыру;
г) кеше башы, аштан баш тарту, ел башы.

4. «Әбиләрнең иске сандыгында… Тукай үзе ята, «Туган тел» (С.Х.)
Бу юлларда нинди лексик күренеш күзәтелә:

а) синоним;

б) пароним;
в) оксюморон;
г) катахреза.

5. Социаль ябык төркемдә яшерен аралашу өчен һәм бу төркемне җәмгыятьтән аеру чарасы буларак кулланыла торган махсус тел –

а) диалекталь сүз;
б) термин;
в) жаргон (арго);
г) һөнәрчелек лексикасы.

6. Түбәндәге сүзләрнең кайсы морфологик диалектизмнарга карый:

а) җайдак, күлдәвек, онта;
б) озаткыч, кәкере, күмәч, бавырсак;
в) яңгылыш, сәңа, кезге (көзге);
г) килең, өченчесенә, киткәчтен.

7. Сүздәге морфеманың чикләре юылу аркасында сүзнең беренчел, мотивлашкан семантик структурасы, мәгънәсе югалуга бәйле лексик-морфологик күренеш –

а) реэтимологизация;
б) деэтимологизация;
в) семантизация;
г) этимология.

8. Бу тел берәмлеге компонентларының мәгънәви кушылуы, мәгънәнең һәм аны белдерүче лексик-грамматик чараларның тотрыклыгы белән аерылып тора.

а) тезмә сүз;
б) сүз;
в) фразеологизм;
г) җөмлә.

9. Түбәндәге сыйфатлар нинди функциональ стильгә хас: логик эзлеклелек, төгәллек, объективлык, терминологик һәм астракт лексиканың күплеге

а) рәсми эш кәгазьләре стиле;
б) публицистик стиль;
в) фәнни стиль;
г) әдәби стиль.

10. Полисемия арасыннан омонимия күренешен күрсәтегез:

а) җир йөзе, йөзе саргаю, пычак йөзе;
б) тау башы, эш башы, кеше башы;
в) зур күзле кеше, энә күзе, сыр күзе;
г) «Синең дә бит, иркәм, Ай битенә пар икән» (Х.Т.)

11. Түбәндәге сүзләр арасыннан кайчандыр бер тамырдан ясалганнарын күрсәтегез:

а) көнчыгыш, башак, юлбашчы;
б) бәрәңге, Бөре, бөер;
в) быел, бүген, буй;
г) пычкы, кыскыч, баскыч.

12. «Антракт вакыты.
Тәти зал уртасында гөрләшеп,
Ак якалар, Пудралар,

Сәнгать хакында серләшеп
әйләнәләр». (Х.Такташ)
Текстта кулланылган күчерелмә мәгънә төрен билгеләгез.
а) метафора;
б) синекдоха;
в) метонимия;
г) вазифа буенча күчеш.

13. «Кош канаты», «самолет канаты» диләр. «Канат» сүзе:
а) сүзнең бер үк мәгънәсе;
б) омоним;
в) күчерелмә мәгънәдә;
г) синоним.

14. Бары тик гарәп-фарсы алынмаларыннан гына торган вариантны билгеләгез:
а) китап, мәктәп, аһәң, шәфкать, галәм, алиһә, ихтирам;
б) китап, аяк, баскыч, кызару, аксыл, дәрес, җир;
в) китап, почта, сары, партия, бүрәнә, фигыль, су;
г) китап, мәхәббәт, яшәеш, көнкүреш, дошман.

15. Түбәндәге вариантларның кайсы «гамьсез» сүзенең синонимик рәтенә тулаем туры килә:
а) ваемсыз, намуссыз, ялкау, кайгысыз, боз йөрәкле;
б) ваемсыз, хафасыз, ис китмәүчән, боз йөрәкле, кайгысыз, кызыксынмаучан;
в) ваемсыз, шәфкатьсез, гыйлемсез, хафасыз, кызыксынмаучан;
г) ваемсыз, риясыз, шифасыз, инсафсыз.

16. Түбәндәге вариантларда «шәфкатьле» сүзенең антонимын табыгыз.
а) аяусыз;
б) итәгатьсез;
в) әдәпсез;
г) хыянәтчел.

17. Түбәндәге вариантлардан «ихтыяҗ» сүзенең синонимын табыгыз
а) мохтаҗлык;
б) хәтер;
в) хөрмәт;
г) ихтыяр.

18. «Ике баш кәбестә», «тау башы», «хикәя башы» дигән сүзтезмәләрдә «баш» сүзе:
а) күчерелмә мәгънәдә;
б) омоним;
в) синоним;
г) сүзнең бер үк мәгънәсе.

19. Вариантларның кайсы «әдәпле» сүзенең синонимик рәтенә тулаем туры килә?
а) тыйнак, әдәпле, тәрбияле, ипле, кыюсыз, тәртипле, ягымлызлек;
б) тыйнак, тәрбияле, белемле, шифалы, ягымлы;
в) әхлакый, тыйнак, тәртипле, инсафлы, тәүфыйлы, күркәм холыклы;
г) тәртипле, шәфкатьле, намуслы, акыллы, фидәкарь.

20. Архаизмнарны билгеләгез:
а) компьютер, бизнес, сайт;
б) мөгаллим, гакыл, хөррият;

в) чабата, СССР, алпавыт;
г) акылдаш, сөюнамә, шигърият, президент.

21. Татар фразеологиясен туплаган, өйрәнгән галимнәрне күрсәтегез:
а) Л. Җәләй, Х. Курбатов, Г. Саттаров;
б) Г. Ахунҗанов, Г. Әхәтов, Н. Исәнбәт;
в) Ф. Гарипова, Г. Саттаров, М. Зәкиев;
г) Р. Әхмәтҗанов, И. Низамов, Ф. Сафиуллина.

22. Антонимия күренеше белән бәйле терминнар төркемен күрсәтегез:
а) экзотизм, варваризм, калька;
б) контрар, комплементар, векторлы, катахреза;
в) абстракт, конкрет, номинатив, сигнал... мәгънә;
г) метафора, синекдоха, метонимия.

23. Сүзнең лексик мәгънәсенә өстәлеп, сүзне эмоциональ, экспрессив, стилистик төсмерләр белән баетучы тел күренеше:
а) мотивация;
б) төшенчә;
в) коннотация;
г) номинация.

24. Чынбарлыктагы әйбер, күренешләрнең гомуми һәм әһәмиятле билгеләрен чагылдыручы фикерләү берәмлеге:
а) сүз;
б) җөмлә;
в) коннотация;
г) төшенчә

25. Ике әйбер, күренешнең охшашлыгы нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә төре:
а) синекдоха;
б) метафора;
в) метонимия;
г) омонимия

**Критерии оценки (в баллах):**
- *6 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *4 балла выставляется студенту, если допущены5-6 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены более 10 ошибок.*

**Задания для письменной контрольной работы № 3**

Җөмләдәге сүзләргә лексик-семантик анализ ясагыз.

**1 вариант**

Минем тормыш дөрес юлдан башланган иде, нишләп язмыш мондый чалыш юлга чыгарды икән дип аптырыйм (З.Хәким).

**2 вариант**

Беркөнне үзәк урамнарның берсендә өстенә кайчандыр затлы булган, әмма вакыт җиле ашап таушалдырган тун кигән җитмеш яшьләрдәге бер агайны абайлап алдым (З.Хәким).

**Критерии оценки (в баллах):**

- *15 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *10 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*
- *8 баллов выставляется студенту, если допущены 4-5ошибок;*
- *4 балла выставляется студенту, если допущены 7 ошибок;*

**Задания для письменной контрольной работы № 4**

1. Тексттагы туры мәгънәле сүзләрне күрсәтегез.
2. Бер сүзнең тулы лексик мәгънәсен ачыклагыз; аны мәгънә типлары буенча анализлагыз(номинатив-сигнал, конкрет-абстракт, туры-күчерелмә, гипоним-гипероним, мотивлашкан-мотивлашмаган, образлы-образсыз, эмоциональ-эмоциональлектән азат, ирекле-бәйле, монолексик-омонимик, терминологик – гомуми,синонимик, антонимик һ.б.);
3. Текстта күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүзләрне (сүзтезмә рәвешендә) табыгыз, күчерелмә мәгънә төрен һәм аларның төрчәләрен күрсәтегез; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
4. Тексттан омонимнарны // омоним табып булырдай сүзләрне күрсәтегез, төрен билгеләгез; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
5. Текстта кулланылган паронимнарны // я паронимик пар хасил итәрдәй сүзләрне табыгыз; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
6. Тексттан синонимнар // синонимик рәткә кертеп булырдай сүзләр табыгыз, төрләрен билгеләгез; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
7. Тексттан антонимнар // антонимик пар компоненты булырдай сүзләр табыгыз, төрләрен билгеләгез; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
8. Тексттагы сүзләрне килеп чыгышы ягыннан анализлагыз; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
9. Сүзләрне кулланылыш даирәсе ягыннан тикшерегез; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
10. Сүзләрне кулланылыш активлыгына карап анализлагыз; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
11. Текстны эмоциональ-экспрессив, стилистик лексик катламнар күзлегеннән тикшерегез; текстның стилен ачыклагыз; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
12. Бер ( берничә) сүзнең этимологиясен ачыклагыз;
13. Текстта кулланылган ономастик берәмлекләрне һәм аларның төрләрен билгеләгез; аларның тексттагы ролен билгеләгез;
14. Тексттагы фразеологизмнарны күрсәтегез, төрләрен билгеләгез; аларның тексттагы ролен билгеләгез.

**1 Вариант**

***

Ишем булып ачалмагач ишегемне,
Ишетсәм дә кагуыңны – ишетмәдем.
Күңел-җаным ачмак булып омтылса да -
Акыл җиңде: тормышыма иш итмәдем.

Язмышымның авторына юк бер сүзем –
Ул исемгә дәгъвә итәм мин бит үзем!..
Һич югында, мин – төп автор хезмәттәше.

Мин җаваплы, очрап куйса хата тезем.

**2 вариант**

***

Авыл йоклый. Карт өянке генә
Авыр сулый, никтер йокламый.
Агач җаны ни әйтмәкче була?
Сызланулы бу өн юккамы?..

Авыл йоклый. Юк бер ут чаткысы.
Бар яктылык – күктән иңгән нур.
Әйтерсең лә, безне бездән яклап,
Безгә сузылган кул – китәр юл.

**Критерии оценки (в баллах*):***

- *15 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *10 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*
- *5баллов выставляется студенту, если допущены 4-5ошибок.*

***Задания для индивидуального опроса № 2***

1. Лексикологиянең төп бурычларын һәм бүлекләрен атагыз.
2. Сүзгә хас төп сыйфатларны билгеләгез.
3. Лексик-семантик мәгънә типларын һәм аларны аерып чыгару өчен нигез принципларны атагыз.
4. Күпмәгънәлелекнең төрләрен һәм төрчәләрен билгеләгез.
5. Килеп чыгыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составының төп төркемнәрен атагыз.
6. Телдәге стилистик катламнарны билгеләгез.
7. Фразеологиянең төркемнәрен күрсәтегез.

**Критерии оценки (в баллах*):***

- *2 балла выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *1 балл выставляется студенту, если допущены 3-4 ошибки.*

***Вопросы для терминологической работы № 3***

1. Төп өйрәнү предметы тотрыклы сүзтезмә булган тел белеме тармагы.
2. Сүзгә хас төп сыйфатлар, билгеләрне атагыз.
3. Кешенең тою органнары ярдәмендә билгеләп була торган күренеш, предметларны белдерүче мәгънә тибы.
4. Чынбарлыктагы аерым предларның, күренешләренең әһәмиятле билгеләре хакында кеше аңында гомумиләштерелеп бирелгән уй-фикер.
5. Сүзнең лексик мәгънәсенең үзеген тәшкил итүче предмет белән бәйләнештәге төшенчәсенә өстәлеп килүче эмоциональ, бәяләү, стилистик төсмергә ия өлеше.
6. Сүзнең атау вазифасын, күренеш-предметларга исем бирү закончалыкларын өйрәнүче лексикология тармагы.
7. Сүзләрнең мәгънәсен, мәгънәләр үсешен өйрәнүче лексикология тармагы.
8. Элек я хәзер булган объектларның ялгызлык атамасын өйрәнүче тел белеме тармагы
9. Сүзнең лексик мәгънәсен тәшкил иткән төп компонентларны атагыз.
10. Сүзнең тарихын, килеп чыгышын өйрәнә торган лексикология тармагы.

11. Предмет-күренешләрне турыдан туры атамый, аларга ишарә генә ясый торган мәгънә тибы.
12. Сөйләмдә аныклау һәм алыштыру - кабатлаулардан арындыру функциясен башкаручы, күренешне төрле яктан ачу өчен кулланыла торган сүзләр.
13. Тотрыклы бәйләнеш нигезендә сүз мәгънәсенең бөтеннән өлешкә, өлештән бөтенгә күчү күренеше, күчерелмә мәгънә тибы.
14. Кешенең тою органнары ярдәмендә билгеләп була торган күренеш, сыйфат, предметларны белдерүче мәгънә тибы.
15. Үзара бәйләнешкә кереп, яңа мәгънәгә ия сүзтезмә хасил иткән антонимик парлар.
16. Яңгыраш һәм язылыш охшашлыгына ия, мәгънәләре белән бер-берсенә бәйләнмәгән (формасы белән тәңгәл, мәгънәсе белән төрле) тел күренеше.
17. Тамырдаш, категориаль мәгънә урталыгына ия, шул ук вакытта мәгънәләре белән аерылган, кулланылышта берсен икенчесе белән алмаштырып булмый торган парлы сүзләр.
18. Ике предмет, күренешнең янәшәлеге, бер-беренә керешүе нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә тибы.
19. Антонимнарның семантик һәм структур төркемнәрен атагыз.
20. Кайсыдыр билгеләре белән охшаш бер төркем предмет-күренешләрнең гомуми атамасы – мәгънә тибы

***Вопросы для терминологической работы № 4***

1. Язылышлары бер төрле, әйтелешләрендә бераз аермалы, тамырдаш булмаган төрле мәгънәле сүзләр.
2. Сүзнең лексик мәгънә типларын атагыз.
3. Сүзнең предмет белән бәйләнештәге төшенчәсенә өстәлеп килүче эмоциональ, бәяләү, стилистик төсмергә ия өлеше.
4. Күренешләрнең охшашлыгы нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә төре.
5. Нинди дә булса охшаш сыйфатларга ия предмет-күренешләрнең җыелма – уртак атамасы, мәгънә тибы.
6. Предмет, эш-хәлләрнең... асыл сыйфатлары хакында кеше аңында гомумиләшкән уй-фикер.
7. Сүзгә хас төп билгеләрне санагыз.
8. Кешенең тою органнары ярдәмендә билгеләп булмый торган күренешләрне белдерүче мәгънә тибы.
9. Лексикология фәненең атама бирү, исем тагу закончалыкларын өйрәнүче тармагы.
10. Төп өйрәнү предметы торыклы сүзтезмә булган тел белеме тармагы.
11. Предмет-күренешләрне турыдан туры атамый, аларга ишарә генә ясый торган мәгънә тибы.
12. Сөйләмдә аныклау һәм алыштыру - кабатлаулардан арындыру функциясен башкаручы, күренешне төрле яктан ачу өчен кулланыла торган сүзләр.
13. Татар теленең төп функциональ стильләрен атагыз.
14. Үзара бәйләнешкә кереп, яңа мәгънәгә ия сүзтезмә хасил иткән антонимик парлар.
15. Килеп чыгышы ягыннан караганда телдәге катламнар.
16. Тамырдаш, категориаль мәгънә урталыгына ия, шул ук вакытта мәгънәләре белән аерылган, кулланылышта берсен икенчесе белән алмаштырып булмый торган парлы сүзләр.
17. Телнең сүзлек составының чыганакларын һәм формалашу процессын өйрәнүче, язуга кадәрге борынгы чорның сүзлек составын реконструкцияләү белән шөгыльләнүче лексикология тармагы.
18. Эмоциональ-экспрессив яктан лексиканың төркемнәрен атагыз.
19. Предмет-күренешләрне турыдан туры атый торган мәгънә тибы.

20. Безнең тормышка хас булмаган, башка халык, милләт, ил мәдәниятенә, яшәү рәвешенә хас күренешләрне атау өчен кулланыла торган алынма сүзләр.
21. Ябык социаль төркемне хезмәтләндерүче, яшерен тел вазифасын башкаручы кулланылыш сферасы (даирәсе) чикләнгән лексика.
22. Телнең үз материалы нигезендә, ләкин чит ил сүзләре үрнәгендә ясалган сүзләр.
23. Территориаль яктан кулланышы чикләнгән лексика һәм аның төрләре.
24. Тотрыклы бәйләнеш, янәшәлек, бер предметның икенчесенә керешүе нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә төре.
25. Алынмаларга каршы көрәш ничек атала?
26. Үз өлкәсендә бердәнбер мәгънәгә ия, төшенчәгә якын я тәнгәл, гомумиләштерү хас булган, фән-техника өлкәсенә караган сүзләр.
27. Сүзнең төп мәгънәдән тыш өстәмә мәгънәләргә ия булуы, ягъни бер сүзнең берничә мәгънә белдерүе.
28. Территориаль яктан кулланышы чикләнгән лексика һәм аның төрләре.
29. Кулланылыштан төшеп калган, югалган предмет, күренешне атаучы сүзләр.
30. Теге яки бу автор тарафыннан уйлап чыгарылган, образ-сурәт тудыруга хезмәт итүче һәм контекстта гына яшәүче яңа сүзләр һәм сүзтезмәләр төркеме.

**Критерии оценки (в баллах):**
- *8 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *6 баллов выставляется студенту, если допущены10 ошибок;*
- *4 балла выставляется студенту, если допущеныболее 20 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущеныболее 30 ошибок.*

### *Типовые задания для письменных ответов на вопросы № 3*

1. Грамматика телне кайсы яклап өйрәнә һәм аның состав өлешләре нинди?
2. Морфологиядә һәм синтаксиста нинди тел берәмлекләре төп өйрәнү объекты булып тора?
3. Грамматик категориягә билгеләмә бирегез.
4. Грамматик мәгънә ул — мөнәсәбәт белдерү дигән төшенчәне сез ничек аңлыйсыз? Грамматик категорияләр ничә төрле була?
5. Нәрсә ул сүз формасы яки сүзформа? Кушымчалар ярдәмендә сүз ясалышын һәм форма ясалышын мисаллар өстендә аңлатыгыз.
6. Грамматик категорияләрнең киң һәм тар мәгънәдә кулланылышын сез ничек аңлыйсыз?
7. «Формалар рәте» һәм «гомумкатегориаль мәгънә» төшенчәләрен сез ничек аңлыйсыз?
8. Татар һәм рус телләрендә нинди типологик уртак һәм үзенчәлекле грамматик категорияләр бар?
9. Функциональ-семантик категорияләр тел төзелешен өйрәнүдә нинди яңа мөмкинлекләр ача?

**Критерии оценки (в баллах):**
- *9 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *7 баллов выставляется студенту, если есть 2 ошибки;*
- *5 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 4 ошибки;*
- *2 балла выставляется студенту, если в работе допущены 6-7 ошибок.*

## *Типовые практические задания № 1 (по словообразованию)*

**1 Вариант**
**Ясалма сыйфатларның дөрес язылышына бәйле артык сүзләрне табыгыз.**

| I. | II. | III. |
|---|---|---|
| А) кар (бабай) | А) кара (бодай) | А) угро (фин) |
| Б) тәрҗемәи (хәл) | Б) тере (суы) | Б) очы (кырые) |
| В) мактау (кәгазе) | В) мело (драма) | В) нәсел (ыру) |
| Г) кара (җимеш) | Г) ак (сакал) | Г) сый (хөрмәт) |
| Д) мюзик (холл) | Д) лиро (койрык) | Д) рәхим (шәфкать) |
| Е) метро (политен) | Е) траги (комедия) | Е) пай (тәхет) |
| Ж) умарта (корты) | Ж) метео (станция) | Ж) каралты (кура) |
| З) туры (сөйләм) | З) микро (район) | З) саф (сата) |
| И) тутырган (тавык) | И) сый (хөрмәт) | И) керем (чыгым) |
| К) нарат (җиләге) | К) тере (көмеш) | К) табан (асты) |

**2 Вариант**
**Ясалма сыйфатларның дөрес язылышына бәйле артык сүзләрне табыгыз.**

| I. | II. | III. |
|---|---|---|
| А) күп (почмаклы) | А) рәтле (башлы) | А) кара (каршы) |
| Б) калкан (сыман) | Б) капма (каршы) | Б) очсыз (кырыйсыз) |
| В) халык (ара) | В) лиро (драматик) | В) туры (сүзле) |
| Г) масса (күләм) | Г) кара (кучкыл) | Г) чал (чәчле) |
| Д) бөтен (дөнья) | Д) озын (борынлы) | Д) хәер (хаклы) |
| Е) пост (позитив) | Е) русча (татарча) | Е) олы (җанлы) |
| Ж) мело (драматик) | Ж) бер (өзлексез) | Ж) зур (күзле) |
| З) ак (сакаллы) | З) озын (озак) | З) керделе (чыктылы) |
| И) мал (мөлкәтле) | И) озынлы (кыскалы) | И) яшькелт (зәңгәр) |
| К) ультра (миләүшә) | К) каурый (каурый) | К) ямь (яшел) |

**Критерии оценки (в баллах*):***
- *8 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *6 баллов выставляется студенту, если есть 2 ошибки;*
- *4 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 4 ошибки;*
- *2 балла выставляется студенту, если в работе допущены 6-7 ошибок.*

## *Типовые практические задания № 2 (по морфологии )*

**1 вариант**

1. **Сыйфатларны табып, морфологик анализ ясагыз**

Әни! Бердәнбер иң кадерле, иң хөрмәтле, иң якын кешебез ул безнең.

Минем әни бу дөньяның
Иң чибәре, сылуы.
Нинди бәхет-

Һәр баланың
Үз әние булуы!
Минем әни, һич бәхәссез,
Иң сөйкемле әни ул!
Әйткән сүзе,
Кылган эше-
Һәммәбезгә туры юл.
Борчыйсым килми әнине,
Елмаеп,
Көлеп йөрсен.
Иң матур әни икәнен
Бөтен дусларым күрсен!

**2 вариант**

1. **Сыйфатларны табып, морфологик анализ ясагыз**

Әниләр! Алар янибызда булса, без-көчлеләр, без- батырлар.
"Әни" диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый
"Әни" сүзен таптарга.

Көннәр якты булсын өчен,
Йокы татлы булсын өчен
Әни кирәк, әни кирәк.
Йокы татлы булсын өчен
Әни кирәк!
Кем тегә матур күлмәкләр,
Кем ясый асыл бизәкләр,
Кем тәмле ашлар пешерә,
Гел сине искә төшерә?

**Критерии оценки (в баллах***)***:**
- *8 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *6 баллов выставляется студенту, если есть 2 ошибки;*
- *4 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 4 ошибки;*
- *2 балла выставляется студенту, если в работе допущены 6-7 ошибок.*

## *Типовые практические задания № 3 (по морфологии)*

1. **Ияртемнәрне һәм аларга нигезләнеп ясалган сүзләрне табыгыз.**

1. Чыр-чу киләләр, көлешәләр, шайтаннар! ***(Ә. Е.)*** 2. Моңарчы бу залда беркем дә ишетмәгән бер көйнең, бер моңның ниндидер бер урынын тотып алды да, тамак белән, дөресрәге, йөрәк белән гөлдер-гөлдер китереп, чирек секундлык кереш ясады. 3. Ул елгачыклар бөтенесе дә юл алган, һәрберсе, чурлап аваз салып, Казанка елгасының мәһабәт салмак шавына кушылганнар иде. ***(М. М.)*** 4. Колхоз председателе һәм Зөфәр шагыр-шогыр атлыйлар. ***(Ә. Е.)*** 5. Караңгы, тын

урамнарда тып-тып тамчылар тама. ***(Ә. Е.)*** 6. Менә шул алдагы атта баручы кешеләрнең баш өсләрендә нидер җылык-җылык уйнаклап куйгалый. (***Ә. Е.)*** 7. Хәтта башакларның бер-берсенә ышкылып кыштырдаулары ишетелә. ***(Ә. Е.)***

**Критерии оценки (в баллах):**
- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если есть 2 ошибки;*
- *6 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 3 ошибки;*
- *4 балла выставляется студенту, если в работе допущены 4 ошибки.*

## *Типовые задания для индивидуального опроса № 3*

**Сүзләрнең язылышын билгеләгез.**

| | |
|---|---|
| | кушылып язылa |
| | аерым язылa |
| | сызыкча аша язылa |

1) Дөнья (күләм)
2) премьер (министр)
3) мөгез (борын)
4) ватан (пәрвәр)
5) контр (атака)
6) төп (төгәл)
7) аз (азлап)
8) елдан (ел)
9) ярты (ел)
10) ярым (утрау)
11) ультра (кыска)
12) кара (алтын)
13) угле (кислота)
14) таш (күмер)
15) көннең (көн) буе
16) дөм (караңгы)
17) ачыктан (ачык)
18) ярты (еллык)
19) икәүдән (икәү)
20) һич (югында)

**Критерии оценки (в баллах):**
- *8 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *6 баллов выставляется студенту, если есть 2 ошибки;*
- *4 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 4 ошибки;*
- *2 балла выставляется студенту, если в работе допущены 6-7 ошибок.*

## *Типовые задания для индивидуального опроса № 4*

| | |
|---|---|
| 1. | Алмашлык – мөстәкыйль сүз төркеме |
| 2. | Алмашлык предметны, аның билгесен, эшенең билгесен, билгесенең билгесен белдерә. |
| 3. | Алмашлык предметны, аның билгесен, эшенең билгесен, билгесенең билгесен турыдан-туры белдерми, ә аларның гомуми мәгънәләренә ишарә итә. |
| 4. | Мәгънәләренә карап, алмашлыклар 7 төркемчәгә бүленәләр. |
| 5. | Кайсы сүз төркеме белән мөнәсәбәттәш булуларына карап, алмашлыклар 6 төркемчәгә бүленәләр. |
| 6. | Алмашлыклар грамматик һәм мәгънә төркемчәләренә бер үк принциптан чыгып бүленә. |
| Алмашлыкларның түбәндәге грамматик төркемчәләре бар:<br>- Исем алмашлыклары<br>- Зат алмашлыклары<br>- Сыйфат алмашлыклары<br>- Сан алмашлыклары<br>- Рәвеш алмашлыклары<br>- Хәл алмашлыклары<br>- Фигыль алмашлыклары<br>- Кисәкчә алмашлыклары | |
| Алмашлыкларның түбәндәге мәгънә төркемчәләре бар:<br>- Сорау алмашлыклары<br>- Зат алмашлыклары<br>- Күрсәтү алмашлыклары<br>- Билгеләү алмашлыклары<br>- Билгесезлек алмашлыклары<br>- Юклык алмашлыклары | |
| 9. | Барлык алмашлыклар да килеш белән төрләнә. |
| 10. | Исем алмашлыклары килеш белән төрләнә. |
| 11. | Сыйфат һәм рәвеш алмашлыклары чагыштыру дәрәҗәсендә кулланыла. |
| 12. | Кайбер сыйфат алмашлыклары рәвеш алмашлыклары урынында кулланыла. |
| 13. | Фигыль алмашлыкларында зат-сан, заман, юклык, юнәлеш формалары күзәтелә. |
| 14. | Татар телендә кайбер зат алмашлыклары килеш белән төрләнми. |
| 15. | Татар телендә зат алмашлыклары тартым белән төрләнә. |
| 16. | Иялек килешендәге зат алмашлыклары тартымның аналитик һәм аналитик-синтетик формаларын белдерә. |
| 17. | Зат алмашлыклары берлек һәм күплек санда кулланыла. |

| |
|---|
| . Күрсәтү алмашлыкларытүбәндәге сүз төркемнәрен алыштырып килә ала:<br>-Сыйфатларны<br>-Саннарны<br>-Рәвешләрне<br>-Кисәкчәләрне |
| 19. Билгеләү алмашлыкларының барысы да исемләшә. |
| 20. Кайбер билгеләү алмашлыклары гомумиләштерүче сүз буларак кулланыла. |
| 21. Билгеләү алмашлыклары җөмләдә җыйнак аныклагыч булып килә. |
| 22. Сорау алмашлыклары аналитик иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара буларак кулланыла. |
| 23. Юклык һәм билгесезлек алмашлыклары сорау алмашлыкларына нигезләнеп ясала. |
| 24. Юклык һәм билгесезлек алмашлыклары белән белдерелгән субъект тарафыннан үтәлгән эш бер-берсеннән аерылмый. |

**Критерии оценки (в баллах):**
- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если есть 5 ошибок;*
- *6 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 10 ошибки;*
- *4 балла выставляется студенту, если в работе допущены 14 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если в работе допущены 19 ошибок.*

## *Типовые задания для письменной контрольной работы № 5*

1. **Билгеләмәләр янына терминнарны язып чыгыгыз.**
2. Азык-төлек, төзү материаллары, химик матдә атамалары.
3. Бер төрдән булган предметларның барысы өчен дә уртак булган исем.
4. Бер төрдән булган предметларның берсен икенчесеннән аеру өчен бирелгән исем.
5. Бер төрдән булган предметларның җыелмасын атый торган сүзләр.
6. *-да,-дә; -та,-тә* кушымчалары белән кулланыла торган килеш. Бу килештәге исемнәр, гадәттә, фигыльләргә иярә, сирәгрәк булса да башка сүз төркемнәренә, мәсәлән исемнәргә, бәйләнеп, хәбәр булырга мөмкин: *Китап **өстәлдә.***
7. *-га,-гә; -ка,-кә* кушымчалары белән кулланыла. Бу килеш грамматик мәгънәләре күп булуы белән аерылып тора. Ул исемнәрне фигыльгә һәм башка сүз төркемнәренә бәйли, җөмләдә төрле хәлләр һәм тәмамлык булып килә.
8. Грамматик мәгънәсе — предметның берлеген белдерү.
9. Затларны, гомумән тереклек ияләрен, предметларны атый торган сүзләр.
10. Исемнәрне башка сүз төркемнәре белән бәйли, алар арасында төрле грамматик мәгънәләр барлыкка китерә һәм аларны төрле җөмлә кисәкләре итеп формалаштыра торган грамматик категогория.
11. Исемнәрнең төп формасы. Аның кушымчалары юк, нуль формада кулланыла. Бу килештәге исемнәр функцияләренең күптөрле булулары белән аерылып тора.
12. Нинди килеш кушымчаларының күбрәк булуы белән аерылып тора.
13. *-ны,-не* кушымчалары белән формалаша. Бу килештәге исем, гадәттә, эшнең туры объектын белдереп, җөмләдә туры тәмамлык була.

14. *-ның,-нең* кушымчалары белән кулланыла, исемнәрне башка бер исемгә, исем фигыльгә яки исемләшкән сүз төркемнәренә бәйли.

15. Предметлыкны белдерә торган сүз төркеме.

16. Предметның бер яки бердән артыклыгын, ягъни билгесез күплеген белдерә торган морфологик категория.

17. Предметның нинди дә булса затка (яки икенче бер предметка) караганлыгын белдерә торган грамматик категория.

18. Санала торган предмет һәм күренеш исемнәрендә билгесез күплекне белдерә.

**2. Исемнәрне табып, аларның грамматик формаларын күрсәтегез**

*Ялда*

Менә бер атна инде без авылда яшибез. Килгәч тә, авылның бөтен тирә-ягын Сабира белән икәү йөреп чыктык. Монда дөнья гаҗәп иркен һәм буш. Иң якын авыл да моннан биш чакрымда.

Без бу зур йортта алты кеше торабыз: Касыйм абзый, Әхмәтша абзый хатыны Бәдернисa апа белән һәм без — өч хатын-кыз. Йортны ике зур эт саклый. Шуның өстенә Касыйм абыйның ау мылтыгы бар.

Ләкин безнең өчен дә, аннары Касыйм абый өчен дә шунысы бик әйбәт —- төннең хәзер иң кыска чагы. Бер яктан караңгылана башлый, икенче яктан әкрен генә сызылып таң да ата башлый.

Сабира белән без икәү күп йөрибез — югыйсә бу озын көнне кая куеп бетерәсең? Вак-төяк эшләрдән, ятып ял итүләрдән соң да әллә никадәр вакыт кала әле. Без еш кына аның белән җиләк җыярга йә кырга, йә елга буйларына китәбез. Кырда оясы-оясы белән җир җиләге пешеп ята, ә елга буендагы куаклыкларда карлыган да бөрлегән, ә тау итәгендә чияләр кызарып ята. Без дә, корзиннарыбызны тутырып, йә җиләк, йә карлыган җыеп кайтабыз. Әнием чүпләп, чистартып, варенье кайнатты, күп итеп киптерде, күп итеп как койды. Аннары ул да бу эштән туйды.

— Җитәр, ташымагыз, кая куеп бетерергә белмим, — диде.

Әнә шулай өч атна вакыт узып та китте. Ял бетте. Әхмәтша абзый безне пар атта Казанга илтә барды. *(Ә. Еники)*

**3.Тест сорауларына җавап бирегез.**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Исем предметлыкны белдерә | |
| 2. | Татар телендә исем төрләнми торган сүз төркеме | |
| 3. | Исемнең 3 грамматик категориясе бар | |
| 4. | Исемнең 4 семантик төркемчәсе бар | |
| 5. | Сан категориясе предметның санын белдерә | |
| 6. | Сан категориясе предметның бер яки бердән күп булуын белдерә | |
| 7. | Сан категорясенең 3 формасы бар | |
| 8. | Сан категорясенең берлек һәм күплек формалары бар | |
| 9. | Татар телендә барлык исемнәр дә берлек һәм күплек санда кулланыла. | |
| 10. | Берлек сан – ялгызлык исемнәрнең гадәти формасы | |
| 11. | Күплек сан кушымчалары һәрвакыт предметның бердән артык булуын белдерә | |
| 12. | Абстракт, җыйма һәм матдә исемнәрендә, ялгызлык исемнәрдә күплек сан кушымчалары башка төрле мәгънә төсмерләре ала. | |
| 13. | Абстракт, җыйма һәм матдә исемнәрендә, ялгызлык исемнәр күплек санда кулланылмый. | |
| 14. | Килеш категориясе исемнәрне башка сүз төркемнәре белән бәйли, алар арасында төрле грамматик мәгънәләр урнаштыра һәм җөмлә кисәкләре итеп формалаштыра. | |
| 15. | Татар телендә килеш нуль формада куланылмый. | |
| 16. | Исемнәр барлык килеш формаларында да объект мәгънәсендә килә. | |

| | |
|---|---|
| 17. Түбәндәге килеш формалары урын-вакыт мәгънәсен белдерә:<br>- юнәлеш килеше<br>- төшем килеше<br>- чыгыш килеше<br>- урын-вакыт килеше | |
| 18. Баш, иялек һәм төшем килешләре субъект-объект килешләре дип йөртелә. | |
| 19. Юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләре урын-ара килешләре дип йөртелә. | |
| 20. Һәр килеш бер генә грамматик мәгънә белдерә ала. | |
| 21. Татар телендә түбәндәге килешләр бар:<br>- баш килеш<br>- иялек килеше<br>- юнәлеш килеше<br>- төшем килеше<br>- чыгыш килеше<br>- урын килеше<br>- вакыт килеше | |
| 22. Тартым категориясе предметның зат белән төрләнүен белдерә. | |
| 23. Тартым категориясе предметның зат-санын белдерә. | |
| 24. Тартым категориясе предметның кайсы затка караганлыгын белдерә. | |
| 25. Тартым категориясе барлык телләрдә дә бар. | |
| 26. Барлык исемнәр дә тартым белән төрләнә ала. | |
| 27. Тартымлы исемнәр килеш белән төрләнми. | |
| 28. Тартым категориясе юнәлеш килешенең мәгънәсенә якын тора. | |
| 29. Иялек килешендәге исемнәрнең грамматик мәгънәләре тартым мәгънәсенә якыная төшә. | |
| 30. Тартымны белдерә торган формалар түбәндәгеләр:<br>- синтетик<br>- аналитик<br>- аналитик-синтетик<br>- нуль форма<br>- *-ныкы/-неке* кушымчалары | |

Описание методики оценивания:

После пройденной темы на изучение имени существительного студенты выполняют контрольную работу, состоящую из 3 частей: в первом задании они должны вписать соответствующие верные термины к каждому определению, во втором – морфологический анализ выделенных существительных и в третьем задании ответить на вопросы путем проставления знаков + или -.

**Критерии оценки (в баллах):**

- *25 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *20 баллов выставляется студенту, если есть 10 ошибок;*
- *15 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 20 ошибок;*
- *10 балла выставляется студенту, если в работе допущены 30 ошибок;*
- *5 балла выставляется студенту, если в работе допущены 39 ошибок.*

***Типовые задания для письменной контрольной работы № 6***

**1. Фигыльләрне тиешле формаларга куеп языгыз.**

Яса (1 зат, б.с., хәз.з.), төй (3 з., к.с., киләчәк үткән з.), ю (2 з., к.с., күптән үткән заман), сау (2 з., б.с., нәтиҗәле үткән заман), сөй (3 з., б.с., шарт ф.), яп (1 зат, к.с., тәмамланмаган үткән з.), кап (3 з. б.с., билгеле кил.з.), тап (инфинитив), көл (3 з., б.с., кабатлаулы үткән заман), ак (боер.ф., 3 з., б.с.), ташы (боер.ф., 2 з., к.с.), яу (1 з., к.с., теләк фиг.) ау (исем ф.), ки (үткән заман сыйф.ф.), тыңла (хәз. з., сыйф.ф.).

**2. Текстны укыгыз. Фигыльләрне табыгыз. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләрне ике баганага аерып языгыз.**

Ике җөпле җилпәзәсенә ябышып, өрәңге орлыклары очып йөри. Аэрочана кебек. Иртәнге җил аларны урман эченнән кырга алып чыккан. Орлыклар табигатьнең шул көченә бирелгәннәр дә шуалар да шуалар. Бичаралар! Сезнең барыгызга да зифа буйлы өрәңге булып утыру насыйп булмас. Җил сезне кырга алып чыгып китәр. Аннан бер үзәнгә хәтле сезне шудырып алып барыр. Сезне кар күмәр. Яз җиткәч, ташу суы агызып китәр сезне. *(М. Мәһдиев)* «Әни» дигән сүз ул йөрәктә туа. Ә йөрәктән чыккан сүз йөрәккә барып керә. «Әни» дип әйттеңме, син инде көчле дә, син инде бәхетле дә. (Я. *Дәүли)*

**3. Хикәя фигыльләрне табыгыз, аларны а) 1з., б.с. теләк фигыльләргә, б) инфинитив формаларына, в) исем фигыльләргә әйләндерегез.**

А) Сузып-сузып, тальян гармун уйный,
Кичке авыл моңга күмелә.
Моң һавада тарала да тына,
Тик таралмый минем күңелдә.
Тальян моңы...
Сабый чагымнан ук Уятмыйча бер төн калмадың.
Син, әтием,
Алам, дия-дия, миңа гармун ала алмадың.

Б) Чөнки беркөн әллә кайда туплар
Гөрелтесе бүлде гармунны.
Син дә киттең Сүндерергә диеп
Илебезгә капкан ялкынны.
Сүнде ялкын, тәрәзәдән карап
Көттем сине, керфек какмадым.
Өй каршыннан узды ничә солдат,
Тик син генә кире кайтмадың.
Хат ташучы апа кертте беркөн
Тәгәлләнми калган хатыңны.

В) «Көт аз гына, улым, — дигәнсең син, —
Язга гармун алып кайтырмын...»
...Сузып-сузып, кемдер гармун уйный.
Тыныч кичләр моңга күмелә.
Ничә еллар, гармун моңы булып,
Син яшисең, әти, күңдемдә...

*(Ш. Маннапов)*

**3. Җөмләләрне укыгыз. Фигыльләрне табып, төркемчәләрен, җөмләдәге функцияләрен билгеләгез.**

1. Соңгы очрашуларда Галина Петровнаны ул шул кыяфәттә истә калдырды. Агара башлаган коңгырт чәч, куе зәңгәр күзләр, тыйнак сабырлык. Шуңа күрә ул аны моңланып, кичке шәфәкъка карап утырган авыру итеп уйлый алмый иде.

Бүген профессорның консультация көне. Ул сәгатенә карап алды да:

— Башлыйк, — диде.

Профессор, урыныннан торып, ишектән килеп кергән кызга каршы атлады. *(Г. Әпсәләмов)*

2. Бабайның сые ул гына түгел. Ел да бер тапкыр, әнә шул җиз казанда кайнаган суга салып, ул безгә кыр үрдәге белән акчарлак йомыркалары да пешереп бирә. *(Ә. Гаффар)*

3. Хәсән ага Туфанның үземдә калган, әле дөнья күрмәгән хатларын кабат-кабат укып утырам.

Шулчак күз алдыма Хәсән ага Туфан үзе килеп баса. Күрешергә кулын суза. Аның ирләр кулына хас булмаган йомшак кулларын учыма алу исемә төшкән саен, аерым бер тоемлау кичерәм. *(Г. Минский)*

**4**. Укыгыз. Фигыльләрнең юнәлешләрен билгеләгез.

1. Киселде башлар... тиделәр...
Тик телгә тидертмәдек;
Агабыз Тукай йөзенә Каралык китертмәдек!..
*(Х. Туфан)*

2. Планеталар нидер ымлашалар,
Күкләргәрәк, өскәрәк менеп...
*(Х. Туфан)*

3. Кулымны бәйләсәләр дә,
Телемне бәйләтмәдем!
*(Х. Туфан)*

4. Эзләдең дә, эзләттең дә,
Җыештың да табыштың Хәтер катламнарындагы Гәүһәрләрен халкыңның.
*(Х. Туфан)*

5. Үткәннәргә кайтыла Тик яңалар аша.
*(Р. Фәйзуллин)*

**5.Фигыльләрне морфемаларга бүлегез. Һәр кушымчаның нинди мәгънә белдерүен әйтегез, алар белән җөмләләр төзеп языгыз**.

Сөйләштергәли, кайткалаштыргалаштыра, көлемсери, килгәли, йокымсырый, елмаештыргалаштыргалый.

**6.Текстны укыгыз. Фигыльләргә тулы морфологик анализ ясагыз.**

Минем китаплар шүрлегендә тавышсыз-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка барган чагында, ул кара дугага тагылган килеш ат башында йөри иде. Хәзер кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та юк, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә менә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган. *(Ә. Еники)*

**Критерии оценки (в баллах):**

- *25 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *20 баллов выставляется студенту, если есть 2-3 ошибки;*
- *15 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 4-5 ошибок;*
- *10 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 6-8 ошибок;*
- *5 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 10 ошибок.*

## *Типовые задания для письменной контрольной работы № 7*

1. Рәвешләрнең төп синтаксик вазыйфасы - ...
1) хәбәр
2) аергыч
3) хәл

2. Рәвешләр ясалышлары буенча...
1) Тамыр, ясалма, парлы, кушма, тезмә, кыскартылма рәвешләргә бүленә
2) Тамыр, ясалма, парлы, кушма, тезмә, конверсияләнгән рәвешләргә бүленә

3. Рәвеш –
1) Эш-хәлнең һәм билгенең билгесен белдерүче мөстәкыйль сүз төркеме
2) Предметның билгесен белдерүче мөстәкыйль сүз төркеме

4. Ясалма рәвешләр...
1) Тегеләй, болай,татарча, әнидәй
2) Аз, еш, күп, сирәк, соң
3) Ачыктан-ачык, төркем-төркем, тиз-тиз, тора-бара
4) Көнозын, берсүзсез, быел, бүген
5) Чын күңелдән, ул арада, көннәрдән бер көнне

5. Кушма рәвешләр...
1) Тегеләй, болай,татарча, әнидәй
2) Аз, еш, күп, сирәк, соң
3) Ачыктан-ачык, төркем-төркем, тиз-тиз, тора-бара
4) Көнозын, берсүзсез, быел, бүген
5) Чын күңелдән, ул арада, көннәрдән бер көнне

6. Парлы рәвешләр...
1) Тегеләй, болай,татарча, әнидәй
2) Аз, еш, күп, сирәк, соң
3) Ачыктан-ачык, төркем-төркем, тиз-тиз, тора-бара
4) Көнозын, берсүзсез, быел, бүген
5) Чын күңелдән, ул арада, көннәрдән бер көнне

7. Тезмә рәвешләр...
1) Тегеләй, болай,татарча, әнидәй
2) Аз, еш, күп, сирәк, соң
3) Ачыктан-ачык, төркем-төркем, тиз-тиз, тора-бара
4) Көнозын, берсүзсез, быел, бүген
5) Чын күңелдән, ул арада, көннәрдән бер көнне

8. Тамыр рәвешләр...
1) Тегеләй, болай,татарча, әнидәй
2) Аз, еш, күп, сирәк, соң
3) Ачыктан-ачык, төркем-төркем, тиз-тиз, тора-бара
4) Көнозын, берсүзсез, быел, бүген
5) Чын күңелдән, ул арада, көннәрдән бер көнне

9. Тамыр рәвешләр...

1) Тамырдан гына тора
2) Рәвеш ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясала
3) Ике тамырдан (сүздән) ясала, сызыкча аша языла
4) Ике яки берничә тамырдан (сүздән) бер-бер артлы тезелеп ясала һәм языла
5) Ике тамырны(сүзне) кушып ясала
6) Бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчү нигезендә ясала

10. Конверся юлы белән ясалган рәвешләр...
1) Тамырдан гына тора
2) Рәвеш ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясала
3) Ике тамырдан (сүздән) ясала, сызыкча аша языла
4) Ике яки берничә тамырдан (сүздән) бер-бер артлы тезелеп ясала һәм языла
5) Ике тамырны(сүзне) кушып ясала
6) Бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчү нигезендә ясала

11. Кушма рәвешләр...
1) Тамырдан гына тора
2) Рәвеш ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясала
3) Ике тамырдан (сүздән) ясала, сызыкча аша языла
4) Ике яки берничә тамырдан (сүздән) бер-бер артлы тезелеп ясала һәм языла
5) Ике тамырны(сүзне) кушып ясала
6) Бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчү нигезендә ясала

12. Ясалма рәвешләр...
1) Тамырдан гына тора
2) Рәвеш ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясала
3) Ике тамырдан (сүздән) ясала, сызыкча аша языла
4) Ике яки берничә тамырдан (сүздән) бер-бер артлы тезелеп ясала һәм языла
5) Ике тамырны(сүзне) кушып ясала
6) Бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчү нигезендә ясала

13. Тезмә рәвешләр...
1) Тамырдан гына тора
2) Рәвеш ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясала
3) Ике тамырдан (сүздән) ясала, сызыкча аша языла
4) Ике яки берничә тамырдан (сүздән) бер-бер артлы тезелеп ясала һәм языла
5) Ике тамырны(сүзне) кушып ясала
6) Бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчү нигезендә ясала

14. Парлы рәвешләр...
1) Тамырдан гына тора
2) Рәвеш ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясала
3) Ике тамырдан (сүздән) ясала, сызыкча аша языла
4) Ике яки берничә тамырдан (сүздән) бер-бер артлы тезелеп ясала һәм языла
5) Ике тамырны(сүзне) кушып ясала
6) Бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчү нигезендә ясала

15. Билге рәвешләре...
1) Эшнең яки хәлнең урынын, вакытын, сәбәбен, максатын белдерә
2) Эшнең, хәлнең,билгенең күләмен һәм үтәлү рәвешен белдерә

16. Хәл рәвешләре...

1) Эшнең яки хәлнең урынын, вакытын, сәбәбен, максатын белдерә
2) Эшнең, хәлнең,билгенең күләмен һәм үтәлү рәвешен белдерә

17. Чагыштыру дәрәҗәсендәге рәвеш...
1) *–рак/-рәк* кушымчалары ярдәмендә ясала
2) *–дай, -дәй, -ча, -чә* кушымчалары ярдәмендә ясала

**2. Җәяләрне ачып, бирелгән рәвешләрне язугыз. Ясалышларына бәйле рәвештә, рәвешләрнең дөрес язылышын аңлатып, нәтиҗә ясагыз.**

Ашык (пошык), йөз (түбән), озын (озак), берсе (көнгә), тик (томалга), тирә (юнь), кызу (кызу), ялан (аяк), бер (көн), бер (өзлексез), тора (бара), көн (озын), бер (тавыштан), көпә (көндез), өр (яңадан), гомер (гомергә), елның (елына), әледән (әле), бер (сүзсез), вакыт (вакыт), бер (гәләшеп), ара (тирә).

**Критерии оценки (в баллах):**
- *15 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *10 баллов выставляется студенту, если есть 6 ошибок;*
- *5 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 12 ошибок.*

.

## *Типовые задания для письменной контрольной работы № 8*

1. Сыйфат фигыльләрдән торган төркемчәне табыгыз.
А) баргач (белү), алып (китү), килүче (кешеләр), ашау (турында уйлау);
Ә) яза (белмәү), алачак (китап), белгән (вакыйга);
Б) уйнаганчы (елау), укып (чыгу), яза-яза (тыңлау), сөйләгәч (белү);
В) укыйсы (газета), китә торган (пассажирлар), кайтучы (кунаклар), менәсе (тау).

2. Татар телендә фигыльләрнең ничә юнәлеш формасы бар?
А) 4;
Ә) 5;
Б) 6.

3. Киләчәк заман хикәя фигыль формаларыннан торган төркемне табыгыз.
А) барыр юл, киләсе елга, дустым әйтер, хат язачак;
Ә) кайтасы көн, китәчәк сәгатьләр, беләчәк мәгълүмат;
Б) мәңге онытмас, иртәгә укыр, мин белмәячәкмен.

4. *Җәяү* рәвешенең төркемчәсен билгеләгез.
А) саф рәвеш;
Ә) күләм-чама рәвеше;
Б) вакыт рәвеше.

5. *Казлар, үзара сөйләшә-сөйләшә, муеннарын боргалый-боргалый, ишегалдындагы зур тагаракта кара-каршы торып* <u>*юыналар*</u> (Г.Б.) җөмләсендәге астына сызылган фигыль формасы —...
А) затланышлы фигыль;
Ә) затланышсыз фигыль.

6. Сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә
1) бәйләгеч сүз төркемнәре;

2) модаль сүз төркемнәре;
3) мөстәкыйль сүз төркемнәре.

7. Мәсьәләне *телдән* чишәбез. Җөмләдә аерып бирелгән сүз ничек ясалган?
1) яңа сүз ясалмаган;
2) тамырга ясагыч кушымча ялганган;
3) икенче сүз төркеменә күчкән;
4) алдагы төркемнәрдә дөрес җавап күрсәтелмәгән.

8. Хәзерге заман сыйфат фигыльнең тезмә (аналитик) формасы...
1) җанлы предметларны гына ачыклый;
2) җансыз предметларны гына ачыклый;
3) җанлы һәм җансыз предметларны ачыклый.

9. Йөкләтү юнәлешендәге фигыльләрне билгеләгез.
1) ярату, киенгәндер, уйландыру,
2) укытамын, карашам, көрәләчәк;
3) очыру, укытачакмын, яшелләндерү

10. Иялек килешендәге исем җөмләдә...
1) ия, аергыч, тәмамлык булып килергә мөмкин;
2) аергыч, тәмамлык булып килергә мөмкин;
3) җөмләнең барлык кисәкләре булып килергә мөмкин.

11. Сыйфат фигыльнең кайсы формасы юклыкта кулланылмый?
1) -учы / -үче;
2) -асы / -әсе, -ыйсы / -исе;
3) -ыр / -ер, -ар / -әр, -р.

12. Рәшидә, яшьләрен йота-йота, *шак-шок* атлап, урам буйлап китеп барды (Ә.Е.) җөмләсендә астына сызылган сүз:
1) рәвеш;
2) ымлык;
3) аваз ияртеме.

13. Билгесезлек алмашлыкларын табыгыз.
А) һичкем, бернәрсә, берни;
Ә) бөтен, үз, һәр;
Б) әллә ни, кемдер, кайдадыр;

14. *Күпмедер вакыт узгач, кызның тагын моңлы җыры ишетелә.* (Ә.Е.) җөмләсендәге сыйфатның дәрәҗәсен билгеләгез.
А) гади;
Ә) чагыштыру;
Б) кимлек;
В) артыклык.

15. *Ул иң элек мәһабәт гәүдәле кордашы белән кочаклашты.* (Ш.Р.) җөмләсендәге фигыльнең юнәлешен билгеләгез.
А) кайтым;
Ә) төшем;
Б) уртаклык;
В) йөкләтү.

16. Аксыл, алсу сүзләрендә -сыл һәм -су кушымчалары:
1) сыйфат дәрәҗәсе ясый;
2) яңа сүз ясый;
3) сүзне төрләндерә

17. *Ирле-хатынлы* сүзе нинди ысул белән ясалган?
1) фонетик;
2) морфологик;
3) морфологик-синтаксик;
4) синтаксик.

18. Татар телендә ничә килеш формасы бар?
1) 6;
2) 7;
3) 8;

19. Астына сызылган исем кайсы заттагы тартым белән төрләнгән? *Авылының* бормалы юлы.
1) 1 зат, берлектә;
2) 2 зат, берлектә;
3) 3 зат берлектә;
4) тартым белән төрләнмәгән.

20. Җөмләдәге тартымлы исем кайсы килештә кулланылган? *Үги ана яфрагын язын җыярга кирәк.*
1) баш;
2) иялек;
3) юнәлеш;
4) төшем;
5) чыгыш;
6) урын-вакыт.

21. Яшькелт - ...
1) асыл сыйфат;
2) нисби сыйфат.

22. 2/3 - бу…
1) чама саны;
2) бүлем саны;
3) тәртип саны;
4) микъдар саны.

23. *Быел имтихан бирелмәде* җөмләсендәге фигыль -...
1) затланышлы;
2) затланышсыз.

24. *Килгәләгез* фигыле нинди юнәлештә?
1) төп;
2) төшем.

25. Киләчәк заман сыйфат фигыльнең
1) өч төре бар;

2) бер төре бар;
3) ике төре бар.

26. Тырышкан табар, ташка кадак кагар (М.) җөмләсендә тырышкан сүзе:
1) аергыч ролендә килгән киләчәк заман сыйфат фигыль;
2) билгесез үткән заман хикәя фигыль;
3) исемләшкән сыйфат фигыль.

27. *Тәрәзәләр яктырып китә. Кулда эш уйнап тора* (М.Галиев) җөмләсендә - ып / - еп кушымчалы хәл фигыль:
1) тезмә фигыль составында төп эшне белдерә;
2) икенче бер фигыльдән аңлашылган төп эшкә өстәмә эшне белдерә;
3) иярчен җөмләнең хәбәре булып килә

28. Уйлата сүзенең - лата өлеше:
1) бер бөтен кушымча — сүз ясагыч;
2) ике кушымча — сүз ясагыч + заман;
3) өч кушымча — сүз ясагыч + юнәлеш + заман.

29. Боерык фигыльнең мәгънәсе
1) эш кушуны, боеруны белдерү;
2) теләкне белдерү;
3) эш, хәл, хәрәкәтнең булу-булмавын хәбәр итү.

30. Инфинитивның юклык формасы түбәндәгечә белдерелә:
1) фигыль нигезенә -ма / -мә кушымчасы ялганып;
2) түгел кисәкчәсе ярдәмендә;

31. Урын-вакыт килешендәге исем…
а) -ка, -кә, -та, -тә кушымчалары ярдәмендә ясала
б) -да, -дә, -та, -тә кушымчалары ярдәмендә ясала
32. Предметның һәм затның билгесенә яки рәвешенә күрсәтүче алмашлыклар...
а) төрләнми
б) төрләнә
33. Тезмә исем эчендә ялгызлык исем булса, ул...
а) юл хәрефеннән языла
б) баш хәрефтән языла
в) һәр сүзе юл хәрефеннән генә языла
34. Урын-вакыт килешендәге исем эш яки хәлнең...
а) урынын һәм вакытын белдерә
б) урынын, вакытын һәм кыек объектын белдерә
35. 0, 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9...
а) гарәп цифрлары
б) рим цифрлары
36. Сорау алмашлыклары:..
а) кем, нәрсә, ни, нинди, кайсы
б) кемдер, нәрсәдер, нидер, ниндидер, кайсыдыр
б) әллә кем, әллә нәрсә, әллә ни, әллә нинди, әллә кайсы
37. Сыйфат - ...
а) процессның һәм билгенең билгесен белдерүче мөстәкыйль сүз төркеме
б) процессның һәм билгенең билгесен белдерүче ярдәмлек сүз төркеме
в) предметның билгесен белдерүче мөстәкыйль сүз төркеме
г) предметның билгесен белдерүче ярдәмлек сүз төркеме

38. Исем алмашлыклары...
  а) төрләнми
  б) сан, тартым, килеш белән төрләнә
  в) дәрәҗә белән төрләнә
39. Сыйфат белән ачыкланып килгән исем...
  а) сыйфатланмыш дип атала
  б) сыйфатланучы дип атала
  в) сыйфатлана торган дип атала
  г) сыйфатлы дип атала
40. Сыйфат алмашлыклары...
  а) төрләнми
  б) сан, тартым, килеш белән төрләнә
41. Исемнәр, ясалышларына карап, ...
  а) 4 төргә бүленә
  б) 5 төргә бүленә
  в) 6 төргә бүленә
42. Сан алмашлыклары...
  а) төрләнми
  б) сан, тартым, килеш белән төрләнә
43. Сыйфатлар төзелешләре буенча...
  а) 4 төргә бүленә
  б) 5 төргә бүленә
  в) күп төрле була
44. Исем алмашлыклары җөмләдә...
  а) аергыч, хәбәр хәл булып килә
  б) аергыч яки хәл булып килә
  в) хәл генә булып килә
  г) ия, аергыч, хәбәр, тәмамлык, хәл булып килә
45. Ясалма рәвешләр...
  а) тамырдан гына тора
  б) рәвеш ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясала
  в) ике тамырдан ясала, сызыкча аша языла
  г) ике тамырны кушып ясала
46. Саннар мәгънәләре буенча...
  а) 4 төргә бүленә
  б) 5 төргә бүленә
  в) 6 төргә бүленә
47. Исемнәрг ялганган –кай, -кәй, -чык, -чек, -кәш кушымчалары – иркәләүне һәм кечерәйтүне белдерүче...
  а) төрләндергеч кушымчалар
  б) төр кушымчалары
  в) сүз ясагыч кушымчалар
48. Урын-вакыт килешендәге исемнәргә -гы, -ге, -кы, -ке кушымчалары ялганып,
  а) урын яки вакыт буенча билге белдерүче нисби сыйфатлар ясала
  б) төрле дәрәҗәдәге сыйфатлар ясала
49. Микъдар саны белән ачыкланган саналмыш...
  а) һәрвакыт күплектә килә
  б) һәрвакыт берлектә килә
  в) күплектә дә, берлектә дә килә
50. Тамыр исемнәр...
  а) ике тамырны кушылып ясала
  б) лексик мәгънәгә ия булган төп берәмлекләр

51. Рәвеш алмашлыклары...
а) төрләнми
б) сан, тартым, килеш белән төрләнә
52. Чама саны…
а) ничә? күпме? сорауларына җавап бирә
б) ничәнче? соравына җавап бирә
в) ничәшәр? күпмешәр? сорауларына җавап бирә
г) ничәү? соравына җавап бирә
д) ничәләп? күпмеләп? сорауларына җавап бирә
53.Билгеләү алмашлыклары зат яки предметларны...
а) аерым-аерым гына белдерә
б) гомумиләштереп кенә белдерә
в) аерым-аерым яисә гомумиләштереп белдерә
54. Тезмә исемнәр...
а) тамырдан гына тора
б) рәвеш ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясала
в) ике тамырдан ясала, сызыкча аша языла
г) ике тамырны кушып ясала
55. Сыйфатларның...
а) тамыр, нигез, күплек, азлык дәрәҗәләре бар
б) төп, чагыштыру, артыклык, кимлек дәрәҗәләре бар
56. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфат...
а) *-рак, -рәк* кушымчасы ярдәмендә ясала
б) *-ла, -лә, ча, -чә* кушымчалары, *бик* кисәкчәсе ярдәмендә ясала
57. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфат...
а) бер предметтагы билгенең икенче бер предметтагы шундый ук билгедән чагыштырмача артык икәнлеген белдерә
б) бер предметтагы билгене икенче бер предметтагы билге белән чагыштыра
58. Билгесезлек алмашлыклары...
а) эшнең яки хәлнең үтәлеше ачык булмауны күрсәтә
б) зат, предмет, билге, сан, рәвеш, хәлләрнең билгесезлеген күрсәтә
59. Тартым белән төрләнгән исемнәр...
а) килеш белән дә төрләнә ала
б) килеш белән төрләнми
60. Асыл сыйфатлар...
а) предметның билгесен аның саф сыйфаты итеп күрсәтә
б) предметның саф билгесен белдермичә, аның берәр урынга, вакытка яки предметка караган булуын гына билгели
61. Мәгънәләре буенча алмашлыклар...
а) 7 төргә бүленә
б) 5 төргә бүленә
в) 6 төргә бүленә
62. Ясалышлары буенча алмашлыклар...
а) 4 төргә бүленә
б) 5 төргә бүленә
в) 6 төргә бүленә
63. Төшем килеше кушымчасы исемне...
а) исемгә генә бәйли
б) фигыльгә генә бәйли
64. Чыгыш килешендәге исем...
а) -на, -нә, -та, -тә, -да, -дә кушымчалары ярдәмендә ясала
б) -нан, -нән, -тан, -тән, -дан, -дән кушымчалары ярдәмендә ясала

65. Саннар төзелешләре буенча...

а) 4 төргә бүленә

б) 5 төргә бүленә

в) 6 төргә бүленә

66. Төшем килешендәге исем эш яки хәлнең...

а) туры объектын белдерә

б) кыек объектын белдерә

в) үтәлү рәвешен белдерә

67. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатларны күрсәтегез.

а) җиңелчәрәк, сирәгрәк, тизрәк, күбрәк

б) салкынрак, тәмлерәк, зуррак, төзрәк

**Вариант I**

Җөмләдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз һәм сүзләрне төзелешләре ягыннан тикшерегез.

*Чишмә ап-ак ташлар арасыннан челтер-челтер итеп агып чыккан* (Г.С.)

**Вариант II**

Җөмләдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз һәм сүзләрне төзелешләре ягыннан тикшерегез.

*Тел өстендә уйлану – өзлексез дәвам итә торган акыл эше* (Ә.Е.)

**Вариант III**

Җөмләдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз һәм сүзләрне төзелешләре ягыннан тикшерегез.

*Шуны әйтә алсаң, үзеңдә дә өмет бар дигән сүз…(*Ш.Г.)

**Вариант IV**

Җөмләдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз һәм сүзләрне төзелешләре ягыннан тикшерегез.

*Эше юкка бүгенге көн бик озын сыман тоелды аңа* (А.Г.)

**Критерии оценки (в баллах):**

- *15 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *10 баллов выставляется студенту, если есть 23 ошибки;*
- *5 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 45 ошибок.*

.

## *Образец тестового контроля по морфологии № 5*

1. Сүзнең тамыры – ...

1) сүзнең төп мәгънәсен белдерүче, ләкин аерым гына кулланыла алмый торган кисәк

2) сүзнең төп мәгънәсен белдерә һәм үзе генә дә кулланыла ала торган мәгънәле кисәк

2. Урын-вакыт килешендәге исем...

1) –ка, -кә, -та, -тә кушымчалары ярдәмендә ясала

2) –да, -дә, -та, -тә кушымчалары ярдәмендә ясала

3. Рәвешнең төп синтаксик функциясе - ...

1) хәбәр
2) аергыч
3) хәл

4. Инфинитив ....
1) боеруны, кушуны белдерә
2) эш яки хәлнең исемен белдерә
3) ниятне, максатны, боеруны, өндәүне, теләкне белдерә һәм –рга, -ргә, -ырга, -ергә кушымчалары ярдәмендә ясала

5. Төшем юнәлешендәге фигыльләрне күрсәтегез.
1) эшләде, керермендер, сөйләгән, кайтачак
2) ачылачак, бирелгәндер, караламдыр
3) сатышкансың, төрешкәннәр, сорашканмын
4) ашаткан, каратасың, саттырган, үстергәннәр
5) тузанланган, ятланган, бикләнгән, чикләнмәгән

6. Боерык фигыль …
1) боеруны, кушуны белдерә
2) эш, хәл, хәрәкәтнең булуын (яки булмавын) хәбәр итә
3) ниятне, максатны, боеруны, өндәүне, теләкне белдерә һәм –рга, -ргә, -ырга, -ергә кушымчалары ярдәмендә ясала

7. Урын-вакыт килешендәге исемнәргә -гы, -ге, -кы, -ке кушымчалары ялганып,
1) урын яки вакыт буенча билге белдерүче нисби сыйфатлар ясала
2) төрле дәрәҗәдәге сыйфатлар ясала

8. Хәзерге заман хикәя фигыль 2 зат боерык фигыльгә ...
1) –а, -ә, -я, -ю кушымчалары ялганып ясала
2) –а, -ә, -ый, -и кушымчалары ялганып ясала

9. Билгесез үткән заман сыйфат фигыль боерык фигыльгә ...
1) –ган, -гән, -кан, -кән кушымчалары ялганып ясала
2) –ганчы, -гәнче, -канчы, -кәнче кушымчалары ялганып ясала

10. Тамырга ялганып, аңардан яңа сүз ясый торган кушымчалар - ...
1) төрләндергеч кушымчалар
2) төр кушымчалары
3) сүз ясагыч кушымчалар

11. Сыйфат - ...
1) билгене һәм билгенең билгесен белдерүче мөстәкыйль сүз төркеме
2) предметның билгесен белдерүче мөстәкыйль сүз төркеме

12. Шарт фигыль …
1) предметның билгесен аның эшенә, хәленә, хәрәкәтенә карап белдерә
2) эш яки хәлнең булуы (яки булмавы) өчен кирәкле шартны белдерә
3) төп фигыльне вакыт, урын яки эшләнүрәвеше ягыннан ачыклый

13. Сыйфат белән ачыкланып килгән исем...
1) сыйфатланмыш дип атала
2) сыйфатланучы дип атала

14. Сыйфат фигыль …
1) предметның билгесен белдерә
2) предметның билгесен аның эшенә, хәленә, хәрәкәтенә карап белдерә
3) төп фигыльне вакыт, урын яки эшләнү рәвеше ягыннан ачыклый

15. Йөкләтү юнәлешендәге фигыльләрне күрсәтегез.
1) барган, эшләрләр, киткәннәрдер, килмәс
2) юынган, киенгәндер, карангач
3) каешланган, тозланган, сузылыр, җәелгән
4) казышканнар, күрешербез, карашам
5) укытам, сөрттергәнсең, үткәргәнсең

16. Төрләндергечләр ...
    1) бер сүзне икенчесе белән бәйләү өчен, сан, тартым, килеш яки зат-сан белән төрләндерә
    2) бер сүздән икенче яңа сүз ясый
    3) шул ук сүзнең кечерәйтү, иркәләү, дәрәҗә, юклык, төркемчә, заман төрләрен төзи
17. Исемнәр, ясалышларына карап, ...
    1) 4 төргә бүленә
    2) 5 төргә бүленә
    3) 6 төргә бүленә
18. Бер үк тамырдан, төрле ясагыч кушымчалар ялгап, ...
    1) синонимнар ясап була
    2) тамырдаш сүзләр ясап була
    3) антонимнар ясап була
19. Үткән заман хикәя фигыль …
    1) ике төрле була
    2) өч төрле була
    3) дүрт төрле була
    4) биш төрле була
20. Киләчәк  заман хикәя фигыль …
    1) ике төрле була
    2) өч төрле була
    3) дүрт төрле була
    4) биш төрле була
21. Исемнәргә ялганган –кай, -кәй, -чык, -чек, -кәш кушымчалары – иркәләү-кечерәйтүне белдерүче ...
    1) төрләндергеч кушымчалар
    2) төр кушымчалары
    3) сүз ясагыч кушымчалар
22. Затланышлы фигыльләр ...
    1) хикәя фигыль, боерык фигыль, шарт фигыль
    2) хәл фигыль, сыйфат фигыль, инфинитив
    3) барлык фигыльләр дә

**Критерии оценки (в баллах):**
- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если есть 4 ошибки;*
- *6 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 9 ошибок;*
- *4 балла выставляется студенту, если в работе допущены 13 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если в работе допущены 18 ошибок.*

## *Образец тестового контроля по морфологии № 6*

1. Тезмә саннар...
    1) ике яки икедән күбрәк сүздән тора, һәр сүзе аерым языла
    2) бер-бер артлы әйтелгән сүздәрдән тора
2. Саннар язуда...
    1) цифр белән генә белдерелә
    2) сүз белән генә белдерелә
    3) цифр яки сүз белән  белдерелә
3. 0, 1, 2, 3, 4, 5, 6...
    1) гарәп цифрлары

   2) рим цифрлары
4. Вакыт чиген белдергән саннар...
   1) сызыкча аша языла
   2) сызык аша языла
5. Саннар белән...
   1) төрле исәп-хисап мәгънәләре белдерелә
   2) микъдар, тәртип, бүлем, чамалау, җыю мәгънәләре белдерелә
6. Микъдар саны белән ачыкланган саналмыш...
   1) һәрвакыт күплектә килә
   2) һәрвакыт берлектә килә
   3) күплектә дә, берлектә дә килә
7. Микъдар саны...
   1) ничә? күпме? сорауларына җавап бирә һәм предметның төгәл исәбен белдерә
   2) ничәнче? соравына җавап бирә һәм тәртип буенча санын белдерә
   3) ничәшәр? күпмешәр? сорауларына җавап бирә һәм тигез өлешләргә бүленешен белдерә
   4) ничәү? соравына җавап бирә һәм җыйма исәбен белдерә
   5) ничәләп? күпмеләп? сорауларына җавап бирә һәм якынча исәбен белдерә
8. Чама саны...
   1) ничә? күпме? сорауларына җавап бирә һәм предметның төгәл исәбен белдерә
   2) ничәнче? соравына җавап бирә һәм тәртип буенча санын белдерә
   3) ничәшәр? күпмешәр? сорауларына җавап бирә һәм тигез өлешләргә бүленешен белдерә
   4) ничәү? соравына җавап бирә һәм җыйма исәбен белдерә
   5) ничәләп? күпмеләп? сорауларына җавап бирә һәм якынча исәбен белдерә
9. Җыю саны...
   1) ничә? күпме? сорауларына җавап бирә һәм предметның төгәл исәбен белдерә
   2) ничәнче? соравына җавап бирә һәм тәртип буенча санын белдерә
   3) ничәшәр? күпмешәр? сорауларына җавап бирә һәм тигез өлешләргә бүленешен белдерә
   4) ничәү? соравына җавап бирә һәм җыйма исәбен белдерә
   5) ничәләп? күпмеләп? сорауларына җавап бирә һәм якынча исәбен белдерә
10. Бүлем саны...
   1) ничә? күпме? сорауларына җавап бирә һәм предметның төгәл исәбен белдерә
   2) ничәнче? соравына җавап бирә һәм тәртип буенча санын белдерә
   3) ничәшәр? күпмешәр? сорауларына җавап бирә һәм тигез өлешләргә бүленешен белдерә
   4) ничәү? соравына җавап бирә һәм җыйма исәбен белдерә
   5) ничәләп? күпмеләп? сорауларына җавап бирә һәм якынча исәбен белдерә
11. Тәртип саны...
   1) ничә? күпме? сорауларына җавап бирә һәм предметның төгәл исәбен белдерә
   2) ничәнче? соравына җавап бирә һәм тәртип буенча санын белдерә
   3) ничәшәр? күпмешәр? сорауларына җавап бирә һәм тигез өлешләргә бүленешен белдерә
   4) ничәү? соравына җавап бирә һәм җыйма исәбен белдерә
   5) ничәләп? күпмеләп? сорауларына җавап бирә һәм якынча исәбен белдерә
12. Җыю санының саналмышы...

1) була
2) булмый
3) я була, я юк

13. Җыю саны җөмләдә...
   1) мөстәкыйль кулланыла
   2) хәбәр белән кулланыла
   3) мөстәкыйль дә (исемнән башка да), хәбәр белән дә кулланыла ала
14. Саналмышсыз килгән саннар...
   1) исемләшми, ләкин төрләнә
   2) исемләшә һәм сан,тартым, килеш белән төрләнә
   3) исемләшә, ләкин төрләнми
15. Исемләшкән сан җөмләдә...
   1) теләсә нинди кисәк булырга мөмкин
   2) иярчен кисәкләр генә булырга мөмкин
   3) баш кисәкләр генә булырга мөмкин
16. Саннар, саналмышлары белән килгәндә, ...
   1) җөмләдә иярчен кисәк (аергыч) хезмәтен үти, тартым белән дә, килеш белән дә төрләнми
   2) җөмләдә баш кисәк хезмәтен үти, тартым белән дә, килеш белән дә төрләнә
17. Сан белән ачыкланган исем...
   1) саналучы дип атала
   2) саналмыш дип атала
18. Төрле саннардан төзелгән саннар...
   1) микъдар саны итеп карала
   2) тәртип саны итеп карала
   3) чама саны итеп карала
   4) җыю саны итеп карала
   5) бүлем саны итеп карала
19. Саннар төзелешләре буенча...
   1) дүрткә бүленә: тамыр, кушма, парлы, тезмә
   2) бишкә бүленә: тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә
20. Кушма саннар...
   1) берничә сүздән тора
2) ике сүздән тора, кушылып языла

**Критерии оценки (в баллах):**
- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 4 ошибки;*
- *6 балла выставляется студенту, если в работе допущены 8 ошибок;*
- *4 балла выставляется студенту, если в работе допущены 12 ошибок.*

## *Типовые задания для терминологической работы № 5*

1. Фигыльгә хас гомуми һәм хосусый грамматик категорияләрне атагыз.
2. Затланышлы һәм затланышсыз фигыль формаларын атап күрсәтегез.
3. Фигыльнең грамматик категорияләре.
4. Хикәяләү наклонениесе һәм аның заманнар системасы.

5. Хәзерге заман хикәя фигыль төрләре
6. Үткән заман хикәя фигыль төрләре.
7. Киләчәк заман хикәя фигыль төрләре.
8. Боеру наклонениесе.
9. Шарт наклонениесе.
10. Теләк наклонениесе.
11. Юнәлеш категориясе, төрләре.
12. Фигыльдә эшнең үтәлү дәрәҗәсен белдерү.

**Критерии оценки (в баллах):**

- *7 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *5 баллов выставляется студенту, если есть 3 ошибки;*
- *3 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 7 ошибок;*
- *1 балл выставляется студенту, если в работе допущены 10 ошибок.*

## *Типовые задания для терминологической работы № 6*

1. Теркәгечләргә ярдәмлек сүз төркеме буларак, семантик, морфологик һәм синтаксик яктан гомуми характерлаучы билгеләмә бирегез.
2. Бәйлек һәм теркәгеч арасындагы уртак һәм аермалы якларны күрсәтегез.
3. Тезүче теркәгечләргә билгеләмә бирегез.
4. Ияртүче теркәгечләр билгеләмә бирегез.
5. Ярдәмлек сүз төркемнәренә билгеләмә бирегез.
6. Мөстәкыйль сүзләргә билгеләмә бирегез.
7. Бәйлек сүз төркемен лексик-семантик, морфологик, синтаксик яктан характерлаучы билгеләмә бирегез.
8. Бәйлек сүзләргә билгеләмә бирегез.
9. Бәйлек ролендә йөрүче ярдәмче исемнәргә мисаллар китерегез.

**Критерии оценки (в баллах):**

- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если есть 2 ошибки;*
- *6 баллов выставляется студенту, если в работе допущены 3-4 ошибки;*
- *4 балла выставляется студенту, если в работе допущены 5 ошибок.*

### Экзаменационные билеты

Структура экзаменационного билета:
Экзаменационный билет состоит из 3 вопросов, 2 из которых теоретические, 1 практический

### Примерные вопросы для экзамена по синтаксису

1. Синтаксисның өйрәнү объекты, синтаксис белән морфология арасындагы мөнәсәбәт.
2. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше, мәгънә белдерүдә катнашуы.
3. Сөйләмнең төп берәмлеге – җөмлә, аның иң мөһим үзенчәлекләре.
4. Кыскартылган (эллиптик) җөмләләр.
5. Хәбәрлек, аның белдерелеше.
6. Өстәлмәләр.
7. Модальлек, аның белдерелеше.
8. Кушма җөмлә. Аның билгеләмәсе, төп үзенчәлекләре.

9. Интонация – җөмләнең мөһим үзенчәлеге.
10. Кушма җөмләләрне төркемләү.
11. Җөмләнең структур схемасы турында гомуми төшенчә.
12. Тезмә кушма җөмлә.
13. Сорау аның төзелеше, интонацион үзенчәлекләре.
14. Иярченле кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Баш җөмлә һәм иярчен җөмләләр. Аларның мәгънәви һәм грамматик үзенчәлекләре, үзара бәйләнеше.
15. Боеру җөмлә, аның төзелеше, интонацион үзенчәлекләре.
16. Синтетик иярченле кушма җөмләләрнең төзелеш үзенчәлекләре.
17. Җөмләгә синтаксик анализ
18. Тойгылы җөмлә. Җөмләдә тойгы белдерүче чаралар.
19. Аналитик иярченле кушма җөмләләрнең төзелеш үзенчәлекләре.
20. Раслау һәм инкяр җөмләләр.
21. Синтетик иярчен җөмләләрнең аерымлануы.
22. Җөмләләрдә сүзләр бәйләнеше. Аның төрләре. Белдерелеш чаралары.
23. Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрнең үзара синонимлыгы, аларның берсен икенчесенә әйләндерү юллары.
24. Җөмләдә ияртүле бәйләнеш, аның төрләре, белдерелеш чаралары.
25. Иярчен җөмләләрне функция ягыннан төркемләү.
26. Җөмләдә тезүле бәйләнеш, аның төрләре, белдерелеш чаралары.
27. Иярчен ия җөмлә.
28. Ярашу, башкарылыш, янәшәлек бәйләнеше.
29. Иярчен хәбәр җөмлә.
30. Сүзтезмәләр. Җөмлә белән сүзтезмә арасындагы мөнәсәбәт. Сүзтезмәләрне төркемләү принциплары.
31. Иярчен тәмамлык җөмлә.
32. Ике составлы җөмлә. Ия составы, хәбәр составы турында төшенчә.
33. Иярчен аергыч җөмлә.
34. Ия, аның белдерелеше.
35. Иярчен хәл җөмләләр, аларның төрләре.
36. Хәбәр, аның төрләре, белдерелеше.
37. Аныклагыч һәм аныклагыч җөмлә.
38. Аергыч, аның белдерелеше, аерылмыш белән бәйләнеше.
39. Кереш сүз һәм кереш җөмлә.
40. Тәмамлык. Аның төрләре. Белдерелеше, үзе караган сүз белән бәйләнеше.
41. Кушма җөмләнең катлауланган төре.
42. Хәл, аның төрләре, белдерелеше, үзе караган сүз белән бәйләнеше.
43. Күп иярченле кушма җөмлә, аның төрләре.
44. Иярчен хәбәр һәм ярымхәбәрлек мәсьәләсе.
45. Катнаш кушма җөмлә.
46. Җөмләгә синтаксик анализ
47. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре.
48. Туры сөйләм.
49. Җөмләгә синтаксик анализ
50. Иярчен кисәкләрнең аерымлануы.
51. Кыек сөйләм. Бер составлы фигыль җөмлә. Аның билгеле һәм билгесез үтәүчеле төрләре.
52. Туры сөйләм янында тыныш билгеләре.
53. Бер составлы исем атау җөмлә.
54. Җөмләнең актуаль бүленеше.
55. Ким җөмләләр.

56. Текст. Анық төзелеше турында гомуми мәгълүмат. Җөмләләрнең структур бәйләнеше.
57. Җөмләнең модаль кисәкләре. Эндәш сүз һәм кереш сүз.
58. Бер составлы, ким җөмләләр, өстәлмәләр арасындагы аерма.

**Образец экзаменационного билета**

БАШКОРТ ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫ

ФИЛОЛОГИЯ ФАКУЛЬТЕТЫ
ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ КАФЕДРАСЫ
ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕ (СИНТАКСИС)

Билет № 23

3. Бер составлы, ким җөмләләр, өстәлмәләр арасындагы аерма.
4. Текст. Анық төзелеше турында гомуми мәгълүмат. Җөмләләрнең структур бәйләнеше.
5. Җөмләгә синтаксик анализ ясагыз: *Сабыйның рухы ни бирсәң, шуны алучан.*

Перевод оценки из 100-балльной в четырехбалльную производится следующим образом:
- отлично – от 80 до 110 баллов (включая 10 поощрительных баллов);
- хорошо – от 60 до 79 баллов;
- удовлетворительно – от 45 до 59 баллов;
- неудовлетворительно – менее 45 баллов.

***Критерии оценки** ответа на экзамене **(в баллах):***

- ***25-30 баллов** выставляется студенту, если студент дал полные, развернутые ответы на все теоретические вопросы билета, продемонстрировал знание функциональных возможностей, терминологии, основных элементов, умение применять теоретические знания при выполнении практических заданий. Студент без затруднений ответил на все дополнительные вопросы. Практическая часть работы выполнена полностью без неточностей и ошибок;*

- ***17-24 баллов** выставляется студенту, если студент раскрыл в основном теоретические вопросы, однако допущены неточности в определении основных понятий. При ответе на дополнительные вопросы допущены небольшие неточности. При выполнении практической части работы допущены несущественные ошибки;*

- ***10-16** баллов выставляется студенту, если при ответе на теоретические вопросы студентом допущено несколько существенных ошибок в толковании основных понятий. Логика и полнота ответа страдают заметными изъянами. Заметны пробелы в знании основных методов. Теоретические вопросы в целом изложены достаточно, но с пропусками материала. Имеются принципиальные ошибки в логике построения ответа на вопрос. Студент не сделал практическое задание или при выполнении допущены грубые ошибки;*

- ***1-10 баллов** выставляется студенту, если ответ на теоретические вопросы свидетельствует о непонимании и крайне неполном знании основных понятий и методов. Обнаруживается отсутствие навыков применения теоретических знаний при выполнении практических заданий. Студент не смог ответить ни на один дополнительный вопрос.*

**Типовые практические задания № 4**

**1 вариант**

**1. Бәйләүче чараларны табыгыз. Сүзтезмәләрне файдаланып, җөмләләр төзегез.**
Безнең авыл, горур кеше, оныгыма бүләк итү, моңа кадәр күрмәү, матурлап язу, офыктагы маяк, синнән алу, капчык-капчык бәрәңге, өй эчендәге урындык, җыргы әйләндерү, күргәнче белмәү, мәкаләне уку, юк-бар сүз.

**2. Сүзтезмәләрне гади һәм катлаулы төрләргә аерыгыз.**
Урам аркылы чыгу, кешеләргә әйтү, урманлы тау, бер иптәш, күрсәң сөйләшү, дүртенче йорт, су буеннан килү, өч пот бодай, киләсе атнада кайту, кәрәзле бал, болынга хәтле озату, сөйли торган курчак, сул кулда гына урнашу, каенлык уртасында тору, күргәч әйтеп салу, акка буяу, сирәк-мирәк язу, куркудан кычкырып җибәрү, чүкеч белән сугу, тау артыннан күренеп тору, матурлап ясау, җырлый - җырлый бару, ике кило шикәр.

**3. Түбәндә төрле сүзләр бәйләнешкә кертелгән, аларның кайсы сүзтезмә, ә кайсылары сүзтезмә түгел?**
Түземсезлек белән, кич якынлашты, кояшның түгәрәге, соры болытлар, иртәнге төсле үк, кызу хәрәкәт, кузгалу вакыты, күздән үткәрү, ир-ат һәм хатын-кыз, төнгә каршы чыгу, кулындагы бала, үсәргә маташа, эт карт, яшь кеше, керфекләре аша.

**4. Сүзтезмәләрдәге ияртүче һәм ияртүче сүзләрнең кайсы сүз төркеменнән икәнен билгеләгез.**
Журнал уку, безнең кунак, ялгыш әйтү, шәһәрдән читтә, соңгы көчем, үз халкым, иртән бару, еш кабатлану, ак челтәр, арыганчы йөгерү, сөйкемле күренү, кискен борылыш, мәктәптән кайту.

**5. Сүзтезмәләргә тулы характеристика бирегез.**

Давыл вакытында күрү, кырмыска оясы, атна саен кайту, беренче укытучы

**2 вариант**

**1. Бәйләүче чараларны табыгыз. Сүзтезмәләрне файдаланып, җөмләләр төзегез.**
Матур чәчәк, киләчәк өчен тырышу, бөтергечтәй бөтерелә, кылычтай үткен, мичкә-мичкә бал, укытучы булып эшләү, язын күрешү, сагынып яшәү, очып китәргә әзер, латин әлифбасы, берәр китап.

**2. Сүзтезмәләрне гади һәм катлаулы төрләргә аерыгыз.**
Урам аркылы чыгу, кешеләргә әйтү, урманлы тау, бер иптәш, күрсәң сөйләшү, дүртенче йорт, су буеннан килү, өч пот бодай, киләсе атнада кайту, кәрәзле бал, болынга хәтле озату, сөйли торган курчак, сул кулда гына урнашу, каенлык уртасында тору, күргәч әйтеп салу, акка буяу, сирәк-мирәк язу, куркудан кычкырып җибәрү, чүкеч белән сугу, тау артыннан күренеп тору, матурлап ясау, җырлый - җырлый бару, ике кило шикәр.

**3. Түбәндә төрле сүзләр бәйләнешкә кертелгән, аларның кайсы сүзтезмә, ә кайсылары сүзтезмә түгел?**
Кара балчык, кояш астында, гөрләвекләр ага, биюче кебек, басу капкасы, ишетелгән җыр, дәрт уяту, ярга ташлану, искә төшү, алтынсу кием, каен төбендә утыру, узып китте, аның артыннан ук, дерт итеп, берничә минут.

**4. Сүзтезмәләрдәге ияртүче һәм ияртүче сүзләрнең кайсы сүз төркеменнән икәнен билгеләгез.**
Биш китап, әйткәч күрү, житди сөйләшү, сезнең кебек аңлату, бер иптәш, җәяү атлау, мондый хәл, русча сөйләү, яздай матур, барып күрү, бөтенләй аңламау, авыл клубы, кайберәүләрне күрмәү.

**5. Сүзтезмәләргә тулы характеристика бирегез.**
Әнисе кебек эшчән, кинәт бору, кыш буе әзерләнү, уйларны бүлдермәү.

**Критерии оценки (в баллах):**
- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если допущены 2 ошибки;*
- *6 баллов выставляется студенту, если допущены 3-4 ошибки;*
- *4 балла выставляется студенту, если допущены 5-6 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 7-8 ошибок.*

**Типовые практические задания № 5**

**1. Җөмләләрне укыгыз. Җөмләнең кайсы кисәкләре (ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык) тиңдәшләнеп килүен әйтегез. Тиңдәш кисәкләрнең үзара нинди чаралар белән бәйләнүләренә карап, тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.**

1) Биектә ак тун ябынган юан болытлар, уң якта яшеллеккә күмелгән урман, икенче якта Иделгә барып тоташкан иңкүлек җәйрәп ята (Т. Галиуллин).
2) Җил болытларны пыран-заран китерде, укмаштырды, таратты, талкыды (М. Әмирханов).
3) Рәтен белеп малны чалу, кышка ит ризыгы, җәйгә казылык, каккан каз, җилдергән ит әзерли белү — татарның милли сыйфатларыннан берсе (М. Галиев).
4) Тышта салкын, караңгы (Г. Әпсәләмов).
5) Бүген көн аяз да, болытлы да (Г. Толымбай).
6) Бу тойгыда җиңелчә генә моң, җиңелчә генә шатлык, нәрсәнедер җиңелчә генә сагыну, нәрсәнедер җиңелчә генә көтү, нәрсәгәдер җиңелчә генә куану, тагы әллә нәрсәләр бар иделәр (Ф. Әмирхан).
7) Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә космонавт та, бер генә академик та чыкмаган. (М. Мәһдиев).
8) Ничәмә көз салкын яңгырлар белән юып ташларга теләгән ул истәлек, ничәмә кыш аяусыз бураннары белән күмеп китмәкче булган — булдыра алмаган (Г. Ахунов).
9) Сул почмакта кечкенә генә, пөхтә генә комодта зур гына көзге, ислемайлар, савытчыклар, хатын-кыз шара-баралары, диварларда әллә ничек кызыл материя белән ясаган чәчәкләр, алар арасында открыткалар. Тынык һава эчендә нечкә генә, пөхтә генә ислемай исе (Г. Исхакый).

**2. Аерымланган хәлләр янында кирәкле тыныш билгеләре куеп языгыз.**

1) Ә менә Кларaның әтисе шул авылда туып-үскән булса да Каракошны сагынып бер дә телгә алмый иде. (Ә. Еники).
2) Сумкасын эчкә урнаштыргач малай үзе дә кереп ятты гәүдәсен тырышып-тырышып баштанаяк салам белән каплады. (Р. Низамиев).
3) Аны күрү белән егет чабаталарын тотып абзарга таба йөгерә дә тиз генә киенеп тә ала. (Әкият).
4) Ул арада диңгез ягыннан ерактагы ташкын тавышы сыман тонык бер шаулау ишетелде. Аның ни икәнен аннан соң тагын нәрсә булачагын абайлап өлгергәнче сулда, пычрак өстендә, озын булып сузылган буразна күренде. (Г. Бәширов)
5) Еракта, бик еракта, тын караңгылыкны нечкә генә нәфис кенә ярып әкиятләрдә алтын кылыч селтәнгән шикелле итеп яшен яшьнәде (Г. Гобәй).
6) Тау-тау болытлар куерып салынкы, кара кучкыл яңгыр болытларына әверелделәр. Каты җил өй түбәсе саламнарын тузгыта, тирәкләр ботакларны җиргә иеп зарланышкан сыман шаулаша башладылар. Һавага күбәләк өере шикелле ап-ак шомырт чәчәкләре тузгып очты (М. Галәү).
7) Күктә, бозлы миләшләрне хәтерләтеп, тәлгәш-тәлгәш йолдызлар кабынды. (Р. Низамиев).

**3. Аерымланган хәлләрне аерымланмаган итеп үзгәртеп язгыгыз. Тыныш билгеләренең үзгәрешен аңлатыгыз.**

1) Эшләрен бетергәч, Мәрзия әби үзе дә түр якка чыкты. (З. Хөснияр).

2) Ул, солдат хезмәтен тутыргач, туп-туры Казанга әнисе ягыннан туган тиешле Хәдичә апаларга кайтып төшә. (З. Хөснияр).

3) Төн буенча авыл урамнарында этләр уладылар. Төн буенча, өй түбәләрендәге саламнарны куптарып, капкаларның тутыгып беткән тупсаларын шыгырдатып, салкын җил шаулады (К. Нәҗми).

4) Кояш, күк читеннән үрмәләп, югары күтәрелә башлады (М. Галәү).

5) Тагын мин, авылымны искә төшереп, еракташ балачагыма иеләм (М. Галиев).

6) Сезнең җырлавыгызны тыңлаганнан соң, мин татар халкының җанын аңлагандай булдым (М. Галиев).

**Критерии оценки (в баллах*)*:**

- *8 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *6 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*
- *4 балла выставляется студенту, если допущены 4-5 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 7 -8 ошибок.*

**Типовые практические задания № 6**

**Җөмләләрне аерымланган хәлле гади җөмләләргә һәм иярченле кушма җөмләләргә аерыгыз, аларны чагыштырып, охшаш якларын табыгыз. Аерымланган хәлләрнең һәм иярчен җөмләләрнең төрен билгеләгез. Тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.**

1. Көне буе баш ватканнан соң, Әнвәрә очрашуга барырга булды. (Ф.С). 2. Ике ай чамасы вакыт узганнан соң, мин аңа хат яздым. (Ф.С.). 3. Өстәлнең ике кеше өчен генә әзерләнгәнен күрсә дә, Альфред андый вак-төяккә игътибар бирмәде. (Ф.С.). 4.Аларның сөйләшергә теләкләре бик зур булсада, Гәүһәр янында чит кеше күргәч, исәнләшеп кенә узып киттеләр. (Г.Ә.). 5. Гәрчә син мине ишетсәң дә, моннан соң арабыз бөтенләйгә өзек булыр. (Ә.Б.). 6. Гәрчә төрле кирмәннәрдә, төрле калаларда яшәсәләр дә, алар – минем азатларым, минем куәтем. ( М.Х.). 7. Кирам картның яшел капкасын киереп ачып җибәрү белән, Зөһрә артыфна авып китә язды. (Г.Г.). 8. Иртәнге кояш күрше йортлар артыннан үрелеп карау белән, ишегалдында пәйда була ул. (Г.Г.) 9. Ниһаять, эш сәгате тәмамланып, хезмәттәшләр таралыша башлады. (Р.Г.). 10. Озакламый, Идел киңлекләренә аш исләре таратып, дәү көймә тулы тизлегенә алга омтылды. (Ф. Л.) 11. Гөлфия басма алдына якынлашкач, ул бер аңа, бер йозаклы ишеккә карап мияуларга тотына. (Ф. Ш.) 12. Заһидулла, бераз ятып хәл җыйгач, капчыгын актарырга керешә. (М. Л.) 13. Яр буена җитәр-җитмәс, Иван суга сикерде һәм бил тиңентен төшеп тә китте. (Ф. Л.) 14. Яз җитәр-җитмәс үк, авылга бер-бер артлы кыш буе читтә, сезонлы эшләрдә йөргән агай-эне кайта башлый.(М. Г -ү) 15. Бүген әзрәк суытып җибәргәнгә, кояшлы һавадан вак-вак энҗе кебек ак кар чаткылары коела. (Г. Б.) 16. Әллә кече яшьтән апасы тирәсендә кайнашканга, кыз кыю булып үсте. (С. С.) 17. Мөсәллим карт белән ныграк аралашкан саен, үз тормышы, яшәеше хакында күбрәк уйланды. (Г.Г.)

18. Дошманнарга нәфрәт арткан саен,
Туган җиргә артты мәхәббәт. (Р.В.)

**Критерии оценки (в баллах*)*:**

- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*
- *6 баллов выставляется студенту, если допущены 4-5 ошибок;*

*- 2 балла выставляется студенту, если допущены 7-8 ошибок.*

**Типовые практические задания № 7**

**1 Вариант**

**Кирәкле тыныш билгеләрен куеп языгыз. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрнең аерым җөмләләре үзара нинди чаралар ярдәмендә бәйләнешкә кергәннәр?**

1) Тәбрик кулларын юмакчы булып иелгән иде бабасы рөхсәт итмәде. (Ә. Баянов).
2) Заһидәнең оеклары лычма су бөтен җире пычранып беткән. (М. Әмирханов).
3) Ярты көннән артык урманда тулганды Җик Мәргән ник бер җан иясе очрасын. (М. Хәбибуллин).
4) Ел артыннан ел узган малай егет булып җиткән. (Әкият).
5) әни тамак кырды әллә нәрсәләр миңа ымлады мин көлә-көлә егеткә сөйли бирдем. (Г. Исхакый).
6) Яр буендагы эсселек кимеде яшькелт дулкыннарның дымлы җиле иркәләде. (М. Әмирханов).
7) Очар кошлар очсын

Зәңгәр күкне кочсын

ә без калыйк туган төбәктә (М. Гыймазетдинов).

8) Ә бит хан кызы үзе дә бик яхшы укый иллә нигәдер һәрчак мөгаллименнән укытасы килә. (М. Хәбибуллин).

**2 Вариант**

**Кирәкле тыныш билгеләрен куеп языгыз. Теркәгечле тезмә кушма җөмләләрнең аерым җөмләләре үзара нинди чаралар ярдәмендә бәйләнешкә кергәннәр?**

1) Үзе күңеленнән шулай дип кабатлады ә үзенең кымшанырлык та әмәле юк иде. (Р. Мөхәммәдиев).
2) Аның күзләренә ишек алдындагы яшел чирәм, бәрәңге бакчасы, түтәлдәге суган-кишерләр, кыярлар чагылып кала да бөтенесен кар күмә. (Ф. Садриев).
3) Чәйнең дә тәме булмады эти, әни берлә дә сүз көйләнмәде. (Г. Исхакый).
4) Хәер, мәчет катындагы кечкенә мәдрәсә булган әмма ләкин электр да, клуб та булмаган. (Ә. Еники).
5) Ләкин ул барысын да шаккаттырып, фән юлыннан китте һәм үзе дә мондый һөнәр сайлауга бер дә үкенми иде. (З. Хөснияр).
6) Ярлылыктан кеше үлми кыйнала тик җан мескен. (Мәкаль).
7) Янә яшен яшьнәде янә күк күкрәде. (М. Әмир).
8) Ә бит хан кызы үзе дә бик яхшы укый иллә нигәдер һәрчак мөгаллименнән укытасы килә. (М. Хәбибуллин).

**Критерии оценки (в баллах):**

*- 10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*

*- 8 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*

*- 6 баллов выставляется студенту, если допущены 4-5 ошибок;*

*- 2 балла выставляется студенту, если допущены 7-8 ошибок.*

**Типовые задания для терминологической работы № 7**

1. Телнең сөйләм төзелешен өйрәнә торган фән

2. Сөйләмнең фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итә һәм сөйләүченең чынбарлыккамөнәсәбәтенбелдерә торган иң кыска берәмлеге
3. Фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итүе, ягъни аларны чынбарлыктан алып чынбарлыкка төбәп әйтүе
4. Сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, сөйләмгә мөнәсәбәт белдерүе
5. Сөйләмнең төп ике үзенчәлеге
6. Бер яки мәгънә ягыннан бәйләнгән берничә сүзне (синтагманы) бер басым астына алып әйтү
7. Җөмләдә мәгънәсе буенча иң әһәмиятле булган сүзгә төшә торган басым
8. Сүзләр бер-берсенә буйсынып килгәндә нинди бәйләнеш була?
9. Сүзләр бер-берсенә буйсынмыйча, үзара тигез хокукта булсалар, нинди бәйләнеш була?
10. Ия белән хәбәр арасында гына була торган бәйләнеш, бу вакытта иярүче сүз (хәбәр) ияртүче сүз (ия) белдергән төшенчә турында нинди дә булса бер яңалык хәбәр итә
11. Иярүче сүз ияртүче сүздән аңлашылган әйберне (төшенчәне) шуңа охшаган башка әйберләрдән (төшенчәләрдән) аерып, конкретлаштырып килә торган бәйләнеш
12. Иярүче сүз, ияртүче сүздән соң килеп, аңа өстәмә аныклык, төгәллек бирә торган бәйләнеш
13. Ике яки берничә мөстәкыйль сүзнең төгәлләүле мөнәсәбәткә екрүе нәтиҗәсендә ясалган һәм төгәлрәк төшенчәне белдерә торган төзелмә
14. Җөмләдә баш килештәге сүз белән бирелеп, хәбәрне үзенә ияртә торган грамматик бәйсез кисәк
15. Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган баш кисәге
16. Җөмләнең барлык кисәкләре дә бер генә баш кисәк янында оешып бетсә, андый җөмлә нинди була?
17. Иясе дә, хәбәре дә булган җөмлә
18. Баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе конкрет билгеле булган бер составлы җөмлә
19. Баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе конкрет билгеле булмаган бер составлы җөмлә
20. Әйберләрнең, билгеләрнең яки төрле күренешләрнең исемнәрен атау юлы белән аларның булу-булмауларын хәбәр итә торган җөмлә
21. Башка сүзләрне ияртеп җәенкеләнә алмый торган сүзләр белән бирелгән җөмлә
22. Җөмләнең предмет төшенчәсен атаучы кисәгенә ияреп, шул предметларның билгесен, санын һәм кемгә (нәрсәгә) каравын белдерүче кисәк
23. Җөмләнең процесс белдерүче сүз белән бирелгән теләсә кайсы кисәгенә ияреп, процессның (яки билгенең) объектын, үтәүчене яки нинди дә булса бер хәл кичерүче әйберне (затны) һ.б. мәгънәләрне белдерүче иярчен кисәк
24. Әгәр тәмамлык процесс турыдан-туры кагыла торган әйберне, төшенчәне белдерсә, андый тәмамлык нинди була?
25. Тәмамлык процесс турыдан-туры кагылмый торган әйберне, затны белдерсә, андый тәмамлык нинди була?
26. Җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш һәм процесс белдерүче башка сүзләр белән бирелгән кисәгенә ияреп, процессның яки билгенең билгесен, яисә процессның үтәлү рәвешен, вакытын, урынын, юнәлешен, максатын, сәбәбен, шартын, күләм-дәрәҗәсен белдерә торган кисәк
27. Процессның яки билгенең булу яки юнәлү урынын белдерә торган кисәк
28. Процессның үтәлү вакытын яки билгенең булу-булмау вакытын белдерә торган кисәк
29. Процессның ничек һәм ни рәвешле үтәлүен яисә нинди дә булса бер хәлнең яки билгенең билгесен, сыйфатын белдерә торган кисәк
30. Процессның яки билгенең күләмен, дәрәҗәсен белдерә торган кисәк
31. Процессның үтәлү-үтәлмәү, билгенең булу-булмау максатын белдерә торган кисәк
32. Процессның үтәлү-үтәлмәү, билгенең булу-булмау сәбәбен белдерә торган кисәк
33. Ияртүче кисәктән аңлашылган процессның киресе булачагын белдерә торган кисәк
34. Ияртүче кисәктән аңлашылган процессның үтәлү-үтәлмәвенә шарт булып тора торган процессны белдерә торган кисәк
35. Ияртүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык кертә торган кисәк
36. Сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, җөмлә эчтәлегенә, төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәкләр

37. Сөйләм төбәлгән затны, әйберне белдерүче сүзләр
38. Сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, төзелешенә һәм сөйләм обстановкасына мөнәсәбәтен белдерүче сүзләр
39. Нинди дә булса бер кисәккә караган һәм шул кисәккә карата бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә торган кисәкләр
40. Аның турында яңалык хәбәр итү өчен алынган төшенчә (һәм аны белдерүче сүзләр)
41. Сөйләм предметы турында яңалык хәбәр итә торган сүзләр (һәм аның эчтәлеге)
42. Җөмләнең ахырына чыгарып, өстәп әйтелгән кисәге
43. Нәрсәне булса да раслаучы җөмлә
44. Нәрсәне булса да инкяр итүче җөмлә
45. Чынбарлыкта булган күренешләр, әйберләр турында хәбәр итүче җөмлә
46. Нинди дә булса сорауны белдергән җөмлә
47. Сөйлүченең боеруын, үтенүен, чакыруын, киңәшен белдерүче җөмлә
48. Көчле тойгы белән әйтелә торган җөмлә
49. Контекст, обстановка, мимика, жестлардан аңлашыла торган кисәге яки сүз формасы кулланылмаган җөмлә
50. Икедән артык хәбәрлеге булган җөмлә

**Критерии оценки (в баллах):**

- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если допущены 8-10 ошибок;*
- *6 баллов выставляется студенту, если допущены 20 ошибок;*
- *4 балла выставляется студенту, если допущены 30 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 40 ошибок.*

**Типовые задания для индивидуального опроса № 5**

**Сүзләр арасында тезүле һәм ияртүле бәйләнешләрне күрсәтегез, бәйләүче чараларын атагыз.**

**1 Вариант**

Мин авылыбызның ... Рамазан чишмәсе буенда утырам. Ул авыл уртасындагы таулык куеныннан агып чыга да, ун адымлап йөгереп баргач, кечкенә елгачык эченә кереп югала.

Елганы чыпчыклар төркеме сырып алган. Алар чыркылдаша-чыркылдаша су чәчрәтеп уйныйлар. Томшыкларына тамчылар алып, күккә чөяләр дә, кабат кабып йотмакчы булып, югары күтәреләләр. Бераздан тагын әйләнеп кайталар!

Чыпчыклар уенына мавыгып, чишмә төбенә килеп төшкән сандугачны күрми дә калганмын икән. Бу ялгыз кош елга суына да, шунда чыркылдашып уйнаган чыпчыклар төркеменә дә исе китмичә, чишмәнең түренәрәк узды. Су буена килеп җиткәч, чишмәгә үрелер өчен, урын җайларга кереште. Аннары үзенең сусап-кибеп беткән томшыгын агымга төртте... (Г. Гыйльман).

**2 Вариант**

Бу вакыйга, ягъни минем мәктәпкә беренче баруым, хәтеремдә мәңге сакланыр. Ул агач ... авылның, бигрәк тә бала-чага белән яшьләрнең һәм хатын-кызларның, иң яраткан урыны булып әверелде (М. Мәһдиев). Аерата төпчек кызлары - игезәкләр - сылу булып үсте (А. Гыйләҗев). Без, малайлар, арба артыннан ияреп йөрибез (Ф. Хөсни) Бу бит – бөтен группаның, бөтен курсның, хәтта факультетның уртак бәйрәме (Ф. Латыйфи). Ә киләчәк, матур киләчәк, мине үзенә чакырып, ашыктырып тора (Ф. Әмирхан). Миңа, елларның иң күп көннәрендә зур шәһәрләрдә тора торган шәһәр баласына, бу кырда үсә торган мең төрле чәчәкләрнең берсенең дә исемнәре мәгълүм түгел (Ф. Әмирхан). Ә иң кечкенәсе - ике яшьтәгесе - тезләнгән килеш капланып яткан (М. Мәһдиев).

**Критерии оценки (в баллах):**
- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*
- *6 баллов выставляется студенту, если допущены 4-5 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 7-8 ошибок.*

**Типовые задания для индивидуального опроса № 6**
**1 вариант**
**Кереш һәм эндәш сүзләр янында кирәкле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Хәер ул башкасын көтмәгән иде дә (Н. Фәттах).
2) Һәрхәлдә Сирин шулай уйлый (Ф. Латыйфи).
3) Ниһаять Наис Гамбәрнең соңга калып та соңармаган шигырьләре беренче китап булып басылып чыкты (М. Галиев).
4) Гаҗәп бит кунак булган җирендә татып караган бик тә тәмле ризык гомерең буена онытылмый, хәтергә сеңеп кала (М. Галиев).
5) Дөресен әйткәндә кеше дигән затның шундый психологиясе аркасында нинди шәп драма әсәрләре дөньяга килгән (М. Галиев).
6) Кыскасы Муса әфәнде дворянский бүлмәгә утыртылган иде (З. Бигиев).
7) Рәхмәт сиңа тормыш (Г. Рәхим).
8) Тотышымны югалттым би! (Н. Фәттах).
9) Әй бөдрә чәч зәңгәр күз
әйтмәм бәгърем авыр сүз (Халык җыры).
10) Инешләрем кая югалдыгыз
Болыннарым кая киттегез?! (В. Фатыйхов).

**2 вариант**
**Кереш һәм эндәш сүзләр янында кирәкле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Әлбәттә бездә махсус «Фал китаплары», «Юраулыклар», «Тәгъбирнамәләр» дә күп булган. (Х. Мәхмүтов).
2) Чыннан да халыкның рухи дөньясы бер әдәбият белән генә чикләнми бит (М. Госманов).
3) Димәк узган тарихны гыйльми объектив рәвештә тулы белер өчен, аны төрле яктан яктырткан чыганакларның да санын ишәйтергә, баетырга кирәк икән (М. Госманов).
4) Бәлкем эченнән генә сагынгандыр, ләкин тыштан бервакытта да күрсәтми иде (Ә. Еники).
5) Иншалла милләтебез шулай бердәм булса, югалып калабыз (Ф. Хәкимова).
6) Алла боерса быелгы елның сентябреннән пансион-мәктәп ачарга телим ( Ф. Хәкимова).
7) Резидәкәй матур ни кайгың бар
Нигә башың түбән иясең? (И. Юзеев).
8) Лачыннарым мин сезгә ышанам, баһадирыгыз йөзенә кызыллык китермәссез (Н. Фәттах).
9) Юксынырбыз сине Остаз! (М. Галиев).
10) Әй Казаным гүзәл шәһре Казаным

Синдә үтте күпме көз һәм язларым.

Синдә сөйдем, синдә ярлар сайладым,

Синдә җайсыз тормышымны җайладым. (Ф. Яруллин).

**Критерии оценки (в баллах):**
- *7 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *5 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*
- *3 балла выставляется студенту, если допущены 5-6 ошибок;*
- *1 балл выставляется студенту, если допущены 8 -9 ошибок.*

**Типовые задания для индивидуального опроса № 7**

**1. Синтетик кушма җөмләләрне укыгыз. Баш һәм иярчен җөмләләрне табып, үзара ничек бәйләнешкә керүләрен аңлатыгыз.**

1) Караңгы төшүгә, Туктамыш тагын бер кат артына әйләнеп карады (Г. Гарифуллин).
2) Көн салкын булса да, ноябрь кояшы үзен сиздерә башлады (М. Галиев).
3) Яңгыр башланганга күрә, алар бар нәрсәләрен җыеп кайтып киттеләр (Г. Әпсәләмов).
4) Китү көннәре җитмәс өчен, ул кулыннан килгәннең барысын да эшләргә әзер иде (Ф. Латыйфи).
5) Көче бар тау күчерер (Мәкаль).
6) Өем минем яктырсын дип,
Ут элдердем шәмнәргә (Л. Лерон).

**2. Синтетик кушма җөмләләрдә тиешле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Ходай кушылдырганны кеше аера алмас. (Мәкаль).
2) Башкалар ду килеп шаулашып шатланышып барганда мин моңаеп барам. (Г. Исхакый).
3) Әти-әнисе аның хәлен белеп торсын дип ул аларга атна саен хат язды (Ф. Хөсни).
4) Үзең тапмаган малның кадере булмас. (Мәкаль).
5) Казларны юып келәт киштәсенә менгереп элгәннән соң кызлар эре көмеш чәчәкләр төшерелгән яшел зәңгәр чиләкләр белән чишмәгә су алырга төшәләр. (Г. Бәширов).
6) Көче бар тау күчерер (Мәкаль).

**Критерии оценки (в баллах):**
- *10 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *8 баллов выставляется студенту, если допущены 1 ошибка;*
- *6 баллов выставляется студенту, если допущены 2 ошибки;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 5 ошибок.*

**Типовые задания для письменных ответов на вопросы № 4**

1. Синтаксис фәненең төп өйрәнү объекты
2. Сөйләм, фикер, әйтү максаты, чынбарлык, сөйләүче һәм тыңлаучы арасындагы мөнәсәбәтләрне билгеләгез
3. Синтаксис һәм логика, сөйләм белән фикерләү арасындагы мөнәсәбәтләрне билгеләгез
4. Сөйләмнең төп үзенчәлеге: модальлек һәм хәбәрлеккә характеристика бирегез
5. Хәбәрлек ничек белдерелә?
6. Модальлек ничек белдерелә?

7. Сөйләм берәмлекләрен атагыз
8. Интонация һәм аның сөйләмдәге ролен билгеләгез
9. Интонациянең төп элементларын атагыз
10. Интонациянең төрләрен атагыз

**Критерии оценки (в баллах):**

- *5 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *3 балла выставляется студенту, если допущены 4 ошибки;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 6 ошибок.*

**Типовые задания для письменной контрольной работы № 9**

**1. Тест сорауларына җавап бирегез**

1. *Сүзтезмә ул —*

а) Ике яки өч мөстәкыйль сүзнең ачыклаулы мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә ясалган һәм төгәлрәк төшенчәне атый торган синтаксик төзелмә;
ә) Өч мөстәкыйль сүзнең хәбәрлекле мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә ясалган сүзләр;
б) тезмә сүзләр җыелмасы.

*2. Хәбәрлекле мөнәсәбәт нигезендә барлыкка килә:*
а) сүзтезмә;
ә) җөмлә;
б) синтагма.

*3. Мөстәкыйль сүзләрнең санына карап, сүзтезмә нинди төрләргә бүленә?*
а) фразеологик;
ә) катлаулы;
б) гади.

*4. Ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, сүзтезмәләр ничә төркемгә бүленә?*
а) 8;
ә) 5;
*б) 7.*

5. Кояш кебек балку *сүзтезмәсенең төзелешен билгеләгез.*
а) гади;
ә) катлаулы.

*6. Мисаллардан сүзтезмәләрне генә аерып языгыз.*
а) стена сәгате;
ә) кура җиләге;
б) тимер юл;
в) күлмәклек тукыма;
г) кычыткан чыпчыгы.

*7.* Яттан сөйләү *сүзтезмәсенең мәгънәви бәйләнешен билгеләгез.*
а) урын мөнәсәбәте;
ә) объект мөнәсәбәте;
б) рәвеш мөнәсәбәте.

*8. Сүзләр арасында нинди бәйләнеш булганда гына, сүзтезмә барлыкка килә?*
а) тезүле;

ә) ияртүле.

*9.Аныклаулы мөнәсәбәтне билгеләгез.*

а) керү белән курку; ә) барырга әзерләнү;

б) карарга дип бару;

в) мактанырга ярату.

*10. Иярүче кисәк ияртүче кисәккә түбәндәге чаралар ярдәмендә бәйләнә:*

а) кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр;

ә) кушымчалар, тезүче теркәгечләр.

**2. Тиешле урыннарда ия белән хәбәр арасына тыныш билгеләре куеп языгыз, кагыйдәләрен аңлатып, нәтиҗә ясагыз. Ия һәм хәбәрләрнең төрләрен билгеләгез**

1) Моң бүтән телләргә тәрҗемә ителми торган, ходай сулышы белән яратылган тылсымлы сүз (М. Галиев).
2) Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, тик һәр йөрәк аны яңарта (Һ. Такташ).
3) Бөтен булган байлыгы урман, чишмәләр һәм кешеләр (М.Мәһдиев).
4) Балам балым, баламның баласы җаным (Мәкаль).
5) Бу Гөлбану өчен икенче сынаш иде, ләкин сер бирмәде (Г. Ибраһимов).
6) Дүрт дүртең уналты.
7) Мин миләүшә чәчәк, ә син горур имән
   Йә син бөркет, ә мин очар юлың туры (Л. Янсуар).
8) Бу борынгыдан килгән сәнгатьнең язылмаган кануны (М. Галиев).
9) Дошманны җиңү өчен иң көчле корал аңа изгелек итү (Р. Фәхретдин).
10) Без гадиләр түгел,
   Без галиләр (З. Насыйбуллин).

**Критерии оценки (в баллах):**

- *25 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *20 баллов выставляется студенту, если допущены 4 ошибки;*
- *15 баллов выставляется студенту, если допущены 8 ошибок;*
- *10 баллов выставляется студенту, если допущены 12 ошибок;*
- *5 баллов выставляется студенту, если допущены 16 ошибок.*

## Типовые задания для письменной контрольной работы № 10

**Тезүле һәм ияртүле бәйләнешне белдерүче чараларның икесе дә кат**нашып **ясалган кушма җөмләләрне табыгыз, бәйләүче чараларның кайсы төргә (каршы куючы, җыючы теркәгеч, мөнәсәбәтле сүз, ияртүче теркәгеч һ. б.) каравын әйтегез. Ике аналитик бәйләүче чаралы җөмләләрне аерып чыгарыгыз.**

1. Хәллә моны, әлбәттә, эшли алмады, һәм шунлыктан кәефе тагын да кырыла төште. (Ф. А.) 2. Әгәр Клара урынында берәр дөнья күргән олы кеше булса, ул бу өйләргә карап авылның үткән тарихын да, бүгенге хәлен дә китаптан укыган шикелле укыр иде. **(Ә. Е.)** 3. Бу аңарда горурлык һәм өстенлек тойгысы уятты. Әмма шул ук вакытта үзе белән алар арасында никадәр тирән аерма барлыгын, үзе яшәгән җиңел, гамьсез тормышның аларда юклыгын, хезмәтнең әле нәрсә икәнен белмәстән, үзенең алар күрмәгән ганимәтләр белән файдалануын, ләкин аларның, шушы аерманы сизгән хәлдә дә, аны әнә ничек якын туган итүләрен ул әчке бер уңайсызлану белән хис итмичә кала алмады. **(Ә. Е.) 4.** Хәер, мәчет

катында кечкенә мәдрәсә булган, әмма ләкин электр да, клуб та булмаган. (Ә. **Е.)** 5. Ул моны, билгеле, бик тели дә иде, шуңа күрә, күпме генә озак вакыт узмасын, ничек тә очрашудан, күрешүдән тыелырга тырыша иде. Ләкин шуның белән бергә ул аны һич оныта алмый иде, сагына иде... **(Ә. Е.)** 6. Шулай итеп, Рәшидәнең күңелендә уяна башлаган бөтен шикләре, үпкәләре тарала да бетә иде. Ләкин шулай да яшь ханым соңгы вакытта беркадәр үзгәрә төште. **(Ә. Е.)** 7. Бөтен хикмәт шунда ки, директорның ашыкмыйча җайлап кына, әмма бик төпле итеп сөйләгән сүзләренә каршы куярлык дәлилләре аның җитәрлек түгел иде. **(Ә. Е.)** 8. Без аны бик соң сиздек һәм шунлыктан.тиешле хәзерлекне күреп бетермәдек. **(Ш. У.)**9. Иске үзе, ә шулай да Горур мәрмәр сарайларда. (С. **Сөл.)**

2. **Иярченле кушма җөмләләрне бер төрдән икенче төргә күчереп язы**гыз.

1. Камил шулкадәр онытылган иде ки, Мәдәниянең тамак кыруын да ишетмәде. **(Г. Б.)** 2. Ул никадәрле сак йөрсә дә, йөргән эзен яшерү өчен ничаклы чараларга керешсә дә, «без капчыкта ятып кала алмады»... **(Г. И.)** 3. Ерактан ак таң беленгәндә, җәйләү аяк өстендә иде инде. **(Г. И.)** 4. Алтынчәч байбичәнең гомерлек гадәте, бар: ул, бер җәйләүдән икенче җәйләүгә күчкәндә, һәрвакыт төя өстендә барырга ярата иде. **(Г. И.)** 5. Хатын-кыз өйне корып йөргәндә, Сарсымбай үзе әле яңа килеп җиткән маллар — бияләр, куйлар, сыерлар арасында иде. **(Г. И.)** 6. Сайлау минуты килеп җиткәнгәчә, дала менә шундый шау-шулар, муга, талашлар эчендә туктаусыз кайнады. (Г. **И.)** 7. Вакыт-соң булса да, килеп, коедан су китереп, самовар куйды... **(Г. И.)** 8. Бер атна үтүгә, югары-түбән ат җибәреп, илне җыйдылар. **(Г. И.)**9. Ул әйтмәсә, син аңардан киләшчә белән дә тартып алалмыйсың. **(Ә. Е.)** 10. Бу юлы да алар аны якларга һәм сакларга тиешләр, чөнки, бердәҢ, ул адарга бик кирәк кеше, икенчедән, кимчелекләр өчен бары бер ул гына гаепле түгел икәнлеген бик яхшы белеп торалар. **(Ә. Е.)** 11. Ишек-капкалар бикле ялан кадәр йортта япа- ялгыз кеше көтеп утыру гомумән җиңел түгел инде ул... **(Ә. Е.)** 12. Иң гаҗәбе шунда ки, кызйл галифеле, ак папахалы Коръән Хафизны хәзрәттән" башка Дәүләткәй кешеләреннән берәү дә күрми. **(Ә. Е.)** 13. Үзе турында мастер нәрсә уйлый икән — Таһирның тизрәк шуны беләсе килде. **(Х. С.)** 14. Колагында әле һаман да Сәйдәшевнең ачы тавышы ишетелеп торган хәлдә, Гаяз ике арадагы кечкенә капка аша Локманнарга керде. **(Х. С.)** 15. Кара кирәк икән, татар күчерүчесе казан корымына нидер кушкан. **(М. Г.)** 16. Игътибар итегез: ай да, көн дә, хәтта сәгать тә бар, ә ел юк! **(М. Г.)**

**Критерии оценки (в баллах):**
- *15 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *10 баллов выставляется студенту, если допущены 8 ошибок;*
- *5 баллов выставляется студенту, если допущены 17 ошибок;*
- *3 балла выставляется студенту, если допущены 20 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 22 ошибки.*

### Типовые задания для письменной контрольной работы № 11

*1 вариант*

1. **Катлаулы кушма җөмләләрдә тиешле тыныш билгеләрен куеп языгыз.**

1) Башта кыш буе буран котырды авыл юлларын урамнарны тирән көрт басты аякланып йөрерлек хәл калмады. (Ф. Бәйрәмова).

2) Кайсы ни әйтсә икенчесе шундук килешә һәм кайсы кая кузгалса икенчесе шундук аның артыннан иярә (М. Маликова).

3) Алмагачлар тирә-якка хуш ис бөрки урман өстендә ак томан тирбәлә чәчәкләрдә шатлык яшьләредәй чык бөртекләре ялтырый. (Г. Сабитов).

4) Алар парлашуга залдагылар бер нәрсәгә игътибар иттеләр кавалер белән дама икесе дә пөхтә матур ак киемнән икесе дә төз сылу гәүдәле икесе дә җилкенеп вальс бииләр һәм аларның биюе

залдагы башка биючеләрнекенә караганда күпкә дәртлерәк нәфисрәк сыгылмалырак иде. (Ә. Салах).

**2. Текстка анализ ясагыз**

...Әби безне авыл чыкканчы озата барды. Ул таягына таянып әкрен генә атлый. Фатих белән безнең йөрәк түзми, тизрәк чабып китәсе, урманга җитәсе килә. Әлеге керәшен авылы шул урман артында ич. Анда барып җитсәк, Микулай дәдәйне табабыз да табабыз инде.

Уф, җилкапкага җиттек. Әби таягына таянып баскан килеш дога кылды да:

— Йә, балалар, Аллага тапшырдык, исән-сау йөреп кайтыгыз,— дип, басу капкасы төбендә басып калды.

Фатих белән җитәкләшеп алга йөгердек. Аякларыбызда җылы оекбашлар белән өр-яңа чабаталар. Әби ул чабаталарны урта урамның Шәйхулла бабайдан үрдереп алдырган иде. Олтанлы булса да киез итекләребез дә бар барын. Тик әби әйтә, озын юлга чабата җиңел була, ди. Дөрес әйтә, аяклар үзләреннән үзләре атлыйлар.

Әнә якында гына урман караеп күренә. Урман артыннан иренеп кенә кояш күтәрелеп килә. Тирә-юньдә ник бер җан иясе булсын. Тып-тын, ап-ак кар дәрьясы. Өстән карасаң, Фатих белән без, мөгаен, шул дәрьяга төшкән ком бөртеге кебек кенә күренәбез булыр. Күңелләр ашкына (Р. Хафизова).

**2 вариант**

1) Алар парлашуга залдагылар бер нәрсәгә игътибар иттеләр кавалер белән дама икесе дә пөхтә матур ак киемнән икесе дә төз сылу гәүдәле икесе дә җилкенеп вальс бииләр һәм аларның биюе залдагы башка биючеләрнекенә караганда күпкә дәртлерәк нәфисрәк сыгылмалырак иде. (Ә. Салах).

2) Көймәче Шамил читтәрәк суга иелгән өянкегә атланып балык кармаклый арырак ялкау гына койрыгы белән чебен куа-куа Актүш черем итә үлән арасында чикерткәләр черкелди дымсу урында күрән-үләннәрдән әкәм-төкәмнәр югарыга үрмәли әйтерсең лә алар күкнең үзенә җитмәкче яр өстендәге таштa ... кара сыртлы җитез кәлтәләр «ялт» итеп үлән арасына чума Идел өстендә кояшта ялтырап көмеш балыклар сикерешә. (Х. Мөдәррисова).

3) Иңкүлектә ялгыз ат утлап йөри күк күкрәгән саен ул муенын турайта да башын тагын ия тышаулы булганга күрә кушаяклап алга сикергәндә яшен яктысы аның ялын ялкын телләре сыман кызарып күрсәтә ат үзе тимерчелек учагыннан чыккан утлы күмергә охшап кала (Ә. Гаффар).

4)Ул бик мөлаем бөтен җире килешле сул яктан юл ясап таралган алтын сары чәче дулкынланып иңнәренә төшкән зәңгәр күзләренең карашы үткен һәм уйчан түгәрәк ак йөзен бераз эрерәк тигез ак тешләре яктырта тулышып торган иреннәренә чиста күңелле кешеләрдә генә була торган бераз кыенсыну катыш эчкерсез елмаю эленгән (М. Мәһдиев).

**2. Текстка анализ ясагыз**

Беркөнне кичкырын Илгиз бәхетсез бияләйне Фирүзә йөри торган сукмакка куеп калдырды. Иртәнгә чаклы, аннары иртәдән кичкә чаклы яткан урынында ята бирде бияләй. Берничә көннән Илгизгә үз бияләе бик кызганыч булып тоелды. Карга батып, бозланып беткән бияләйне ул өйгә алып кереп җылытты, киптерде дә Фирүзәләр йорты каршындагы өрәңге ботагына чыгарып элде. Әнә шул көннән бирле ботакта тирбәлә дә тирбәлә сыңар бияләй.

Дөрес, апрель урталарында — күләгәле урыннарда кар атаулары агарып ята иде әле — Фирүзә дә тотып карады бияләйне. Әнисе алып бирде аны Фирүзәгә. Илгиз, тәрәзә рамына ябышкан көе, нәрсә була инде, дип, уйлый гына башлаган иде, Фирүзә нәрсәдер әйтте дә, тегеләр бияләйне үз урынына элеп, ипи кибетенә таба киттеләр. Бер-берсенә карап сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә киттеләр. Илгиз тырнак очын кимерә-кимерә, алар кибет борылышына кереп күздән югалганчы, артларыннан карап калды.

Әллә үзен, әллә бияләен кызганып елады инде Илгиз ул көнне. Үзе еламыйм-еламыйм, дип уйласа да, яңаклары буйлап тәгәрәгән кайнар тамчылар, елыйсың-елыйсың, дип үртәделәр аны һәм тагын да ныграк елыйсын китерделәр (Ф. Шәфигуллин).

**Критерии оценки (в баллах):**
- *15 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *10 баллов выставляется студенту, если допущены 2-3 ошибки;*
- *5 баллов выставляется студенту, если допущены 4-5 ошибок;*
- *3 балла выставляется студенту, если допущены 7-8 ошибок;*
- *2 балла выставляется студенту, если допущены 10 ошибок.*

**Типовые задания для тестового контроля № 7**

1. Сүзләр бер-берсе белән бәйләнешкә кереп, …
а) сүзләр бәйләнешен барлыкка китерә
б) җөмлә барлыкка китерә
в) сөйләм барлыкка китерә
2. Аергычны ияртеп килгән сүз…
а) аерылмыш була
б) аныклагыч була
3. Тиңдәш кисәкләр…
а) – өтер аша язылучы җөмлә кисәкләре ул
б) үзара бәйләнештә торып, бер үк сүзгә карыйлар; бер үк функцияне үтәп, җөмләнең бер үк кисәге булалар
4. Ияртүле бәйләнеш…
а) аныклаулы, хәбәрлекле, төгәлләүле мөнәсәбәт ярдәмендә белдерелә
б) тезү (санау), каршы кую интонациясе, тезүче теркәгечләр ярдәмендә белдерелә
5. Туры тәмамлык – …
а) ияртүче сүзгә төшем килеше кушымчасыннан тыш чаралар ярдәмендә ияреп килүче тәмамлык ул
б) төшем килеше кушымчасы алган (яки алу ихтималы булган) тәмамлык ул
6. Тезүле бәйләнеш …
а) тезүче теркәгечләр ярдәмендә яки тезү интонациясе ярдәмендә тормышка ашырыла
б) кисәкчәләр, бәйлекләр, бәйлек сүзләр ярдәмендә тормышка ашырыла
7. Сүзләр арасында аныклаулы мөнәсәбәт булганда, …
а) аныклагычлар барлыкка килә
б) бер сүз икенче сүз турында хәбәр итә, бу очракта җөмлә барлыкка килә
в) бер сүз икенче сүзне ачыклап килә, бу очракта сүзтезмә барлыкка килә
8. Урын хәле – эшнең яки хәлнең…
а) үтәлү урынын һәм вакытын белдереп, фигыльгә буйсынып килүче иярчен кисәк
б) үтәлү вакытын белдереп, фигыльне ачыклап килүче иярчен кисәк
в) үтәлү урынын белдереп, фигыльгә буйсынып килүче иярчен кисәк
9. Ике составлы җөмләләрдә …
а) оештыручы үзәк бер генә була, икенчесен өстәп тә булмый
б) оештыручы үзәк ике – ия һәм хәбәр
10. Тезмә сүз …
а) бербөтен була, бер төшенчәне гомумиләштереп атый
б) теге яки бу төшенчәне ачыклап күрсәтә
11. Шарт хәле – эшнең яки хәлнең…
а) шартын һәм ничек үтәлүен белдереп, фигыльгә буйсынып килүче иярчен кисәк
б) ничек үтәлүен белдереп, фигыльне ачыклап килүче иярчен кисәк

в) шартын белдереп, фигыльгә буйсынып килүче иярчен кисәк

12. Сүз җөмләләрдә …

а) бер баш кисәк кенә була

б) икенче сүз өстәп булмый

в) берничә сүз дә булырга мөмкин

13. Сүзтезмәдә…

а) мөстәкыйль мәгънәле берничә сүз була, алар бер төшенчә белдерә, таркалмыйлар

б) кимендә ике мөстәкыйль мәгънәле сүз була, алар, үзара төгәлләүле мөнәсәбәткә кереп, бер төшенчә белдерә

14. Урын хәле үзен иярткүче фигыльгә…

а) килеш кушымчалары, бәйлек яки бәйлек сүзләр, янәшә тору юлы белән ияре

б) килеш кушымчалары, бәйлек яки бәйлек сүзләр, хәл фигыль кушымчалары, янәшә тору юлы белән ияре

15. Тулы җөмләдә…

а) мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган кисәкләрнең кайберләре кулланылмый да кала

б) мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган кисәкләрнең барысы да була

16. Җөмлә …

а) төрле интонация белән укылырга мөмкин

б) һәрвакыт билгеле интонация белән әйтелә, укыла

17. Күләм хәле үзен иярткүче фигыльгә…

а) рәвешләр, бәйлек яки бәйлек сүзләр ярдәмендә ияре

б) хәл фигыль кушымчасы, чагыштыруны белдерүче –дай/-дәй, -ча/-чә кушымчалары; бәйлек яки бәйлек сүзләр, янәшәлек юлы белән ияре

15. Өстәлмә…

а) хәбәр итү үзлегенә ия булган ким җөмлә

б) оешып беткән җөмләгә өстәлеп килгән сүз

16. Җөмләне укыгандагы тавыш хәрәкәте…..

а) җөмләнең төзелешенә бәйле була

б) җөмләнең төзелешенә бәйле булмый

17. Шарт хәле үзен иярткүче фигыльгә…

а) шарт (яки хәл) фигыльгә да, дә, та, тә кисәкчәләре өстәлү, боерык фигыль формасы; бәйлек сүзләр ярдәмендә ияре

б) шарт фигыль кушымчасы, бәйлек сүз, сорау кушымчалалары ярдәмендә ияре

18. Җөмләдәге сүзләрнең туры тәртибе булганда, …

а) ия– хәбәрдән, аергыч – аерылмыштан, тәмамлык һәм хәлләр – үзләре ияргән сүздән алда, аныклагыч аныкланмыштан соң килә

б) сүзләр, үзләренең гадәти урыныннан күчерелеп, башкача урнаштырылырга да мөмкин

19. Боерык җөмлә…

а) сөйләүченең ихтыярын – эшкә кушуын, үтенүен, өндәвен, боеруын белдерә

б) сорау интонациясе белән әйтелә, сорау алмашлыклары яки сорау кисәкчәләре ярдәмендә ясала

в) тыныч, салмак тавыш белән әйтелә һәм, гадәттә, хәбәр белән тәмамлана

20. Аныклагыч үзен иярткүче сүзне …

а) ачыклап килә

б) ачыкламый, аның мәгънәсенә аныклык, төгәллек кенә өсти

21. Аергыч …

а) предметны, затны белдерә

б) предметның билгесен белдерә

в) эшнең үтәлү урынын, вакытын, максатын, сәбәбен белдерә

22. Тойгылы җөмләләр ярдәмендә…

а) кешегә хас булган тойгылар – шатлану, кайгыру, соклану, үкенү, шикләнү, курку, ис китү теләк һ.б.

б) хикәяләү, белергә теләү, боеру, кушу, үтенү кебек мәгънәләр белдерелә

23. Эндәш сүзләр –

а) сөйләүченең чынбарлыкка, сөйләм эчтәлегенә мөнәсәбәтен белдерүче сүзләр алар

б) сөйләм төбәлгән затны белдерүче кисәкләр

24. Тәмамлык…

а) исем яки исем урынында килгән башка сүз төркемнәре белән белдерелә

б) гадәттә, сыйфат яки исем, рәвеш белән белдерелә

в) гадәттә, рәвеш яки исем, фигыльләр белән белдерелә

25. Раслауны белдерүче җөмләләрдә…

а) сүзләрдән соң инкарь итүне белдерүче сүз һәм кушымчалар булмый

б) фигыль составында юклык кушымчалары, фигыльдән кала сүз төркемнәре янында *түгел* яки *юк* сүзе, *-сыз, -сез* кушымчасы була

26. Җәенке җөмлә…

а) баш һәм иярчен кисәкләрдән төзелә

б) баш кисәкләрдән генә төзелә

27. Гади җөмләдә …

а) ике яки икедән күбрәк хәбәрлек була

б) бер генә хәбәрлек булла

28. Фикерне йомгаклауны белдерүче кереш сүзләрне күрсәтегез

а) башлыча, ниһаять, ахры, ичмасам

б) шулай итеп, димәк, кыскасы, җыеп әйткәндә

в) беренчедән, икенчедән, өченчедән

29. Гади ия…

а) бер генә сүз белән белдерелә

б) тезмә сүз белән белдерелә

в) бер һәм берничә сүз белән белдерелә

30. Тотрыклы сүзтезмәләр – …

а) тезүле һәм ияртүле  бәйләнештәге сүзләр

б) сөйләм барышында, кирәк вакытларда гына төзелгән сүзләр тезмәсе

в) кисәкләре арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләре югалу нәтиҗәсендә таркалмый (үзгәрми) тотрыклы сүзтезмәләр

**Критерии оценки (в баллах):**

- *25 баллов выставляется студенту, если все задания выполнены правильно;*
- *20 баллов выставляется студенту, если допущены 5-6 ошибок;*
- *15 баллов выставляется студенту, если допущены 12 ошибок;*
- *10 баллов выставляется студенту, если допущены 18 ошибок;*
- *5 баллов выставляется студенту, если допущены 24 ошибок.*

### Типовые задания для тестового контроля № 8

**1. Синтаксис**

1) сүзләр бәйләнешен өйрәнә;
2) җөмләләр бәйләнешен өйрәнә;
3) сөйләм төзелешен (сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешен) өйрәнә;
4) сүзтезмәләрне өйрәнә

**2. Сөйләмне оештыруда беренче дәрәҗәдәге рольне**

1) хәбәрлекле мөнәсәбәт уйный;
2) төгәлләүле мөнәсәбәт уйный;
3) аныклаулы мөнәсәбәт уйный.

**3. Сүзләр бәйләнеше арасыннан хәбәрлекле мөнәсәбәтне билгеләгез:**

1) хат сиңа;
2) укыса, сөйләү;
3) шәһәрдә тору;
4) укый торган китап.

**4. Сүзләр бәйләнеше арасыннан ачыклаулы мөнәсәбәтне билгеләгез:**

1) гүзәлсең син;
2) Тукайның, бөек шагыйрьнең;
3) Кара диңгез;
4) урам буеннан йөрү.

**5. Сүзләр бәйләнеше арасыннан аныклаулы мөнәсәбәтне билгеләгез:**

1) син яраткан чәчәкләр;
2) эшли-эшли ару;
3) дусларның, бигрәк тә Нуриянең;
4) Дамир — эшмәкәр.

**6. *Мәрьям өчен авыр* сүзтезмәсендә:**

1) максат мөнәсәбәте;
2) билге мөнәсәбәте;
3) объект мөнәсәбәте;
4) рәвеш мөнәсәбәте.

**7. Җөмләнең структур үзәген төзүче иң әһәмиятле кисәкләр булып**

1) баш кисәкләр килә;
2) иярчен кисәкләр килә;
3) модаль кисәкләр килә;
4) аныклагычлар килә

**8. Я, рәхим итегез, Гали абзый, яраткан коймагыгыздан авыз итегез. (Г.Ә.). Бу җөмләнең иясе булып килә:**

1) Гали абзый;
2) иясе юк;
3) ким җөмлә, иясе кулланылмаган.

**9. Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны тындырмый (М.) җөмләсендә ия булып:**

1) җылы, салкын сүзләре;
2) салкын сүзе;
3) сөяк, салкын сүзләре килә

**10. *Кайтып җитсәм, бер туйганчы елыйм сиңа ятып, яшел чирәмем!* (С.Сөләйманова) җөмләсендә *туйганчы* сүзе**

1) вакыт хәле;
2) рәвеш хәле;
3) күләм хәле;
4) хәбәр булып килә

**11. *Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп* (Г.Тукай) җөмләсендә *утынга* сүзе**

1) туры тәмамлык;
2) кыек тәмамлык;
3) максат хәле;

4) сәбәп хәле булып килә

**12.** ***Бик борынгыдан бабалар аша миңа да килеп җиттең.***
***Бирдең аң, Бирдең белем.***
***Хәзер индеОфыктагы маяк булып алга чакыр, татар теле, Тукай теле! Туган телем!*** **(Акъегет).**
**Әлеге шигырь юлларында бирелгән җөмләләр:**
1) бер составлы билгеле үтәүчеле җөмләләр;
2) бер составлы билгесез үтәүчеле җөмләләр;
3) ике составлы җөмләләр;

**13. Үз** ***бусагаңнан чыгып киттеңме, туган җиреңне аңлый башлыйсың, ныграк сагынасың*** **(А.Гыйлаҗев) җөмләсе:**
1) ким җөмлә булып килә;
2) гомуми үтәүчеле җөмлә;
3) билгеле үтәүчеле җөмлә.

**14. Фразеологик сүзтезмәне табыгыз.**
**А)** Ватанны саклау;
Ә) яхшы кеше;
Б) башны ташка бәрү;
В) агачтан ясау,

**15. Фигыльле исем сүзтезмәне табыгыз.**
А) алмагач утыртасы урын;
Ә) кирәк кадәр икмәк;
Б) хат язарга ашыгу;
В) авыл аркылы үтү.

**16. Кушма фигыль хәбәрле җөмләне табыгыз.**
А) Кояшның соңгы нуры күздән югалды (Г.Б.);
Ә) Ә язмыш аңа каршы барырга әйтә (И.Г.);
Б) Ә хәле аның җилкә кашырлык (Ә.Е.);

**17. Максат хәле булган җөмләне табыгыз.**
А) Аның әрнүдән йокылары кача иде (Г.И.);
Ә) Минем күзләрем ул хәтле җете түгел, алай да күрәм (Г.Б.);
Б) Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп (Г.Т.).

**18. Дөрес раслауны билгелзгез.**
А) Җөмләнең барлык кисәкләре дә тиңдәш була;
Ә) Җөмләнең баш кисәкләре тиңдәш була ала;
Б) Җөмләнең иярчен кисәкләре тиңдәш була.

**19. Хәбәрлекнең санын билгеләгез.**
*Качаклар, ял өчен яшерен урын табылганга шатланып, Григорий артыннан киттеләр* (А.Р.)
А) бер;
Ә) ике;
Б) өч.

**20. Синтаксисның өйрәнү объекты —**
1) сүз төркемнәре системасы;

2) шәһәр һәм авыл атамалары;
3) сөйләм төзелеше;
4) сүз ясалыш юллары.

**21.** ***Бармак аша карау, күз ачып йомганчы, колак салу, тел әйләнми, алтын куллы.*** **Бу —**
1) ирекле сүзтезмәләр;
2) тотрыклы сүзтезмәләр;
3) җөмләләр.

**22. Күпнокта урынына нинди тыныш билгесе куела:** ***Менә минем актык сүзем шул ... мин, Галия үзе риза булмаса, Вәлиевләргә бирмим*** **(Г.И.).**
1) ике нокта;
2) сызык;
3) өтер;
4) күпнокта.

**23. Үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә ничек атала?**
1) тезмә кушма җөмлә;
2) иярченле кушма җөмлә

**24.** ***Чиләк-чиләк бәрәңге, кәрзин-кәрзин алма*** **сүзтезмәләрендә бәйләүче чара:**
1) янәшәлек;
2) сүзләрне кабатлау;
3) сүз тәртибе.

**25. Аналитик иярчен җөмлә баш җөмләгә карата ничек урнаша?**
1) баш җөмләдән алда гына килә;
2) баш җөмләдән алда һәм аннан соң да килә ала;
3) баш җөмләдән соң гына килә.

**26. Бер составлы фигыль җөмләләргә карамаган төрне күрсәтегез:**
1) билгеле үтәүчеле;
2) билгесез үтәүчеле;
3) гомуми үтәүчеле;
4) атау.

**27.** ***Ике кечкенә малай, исләре китеп, кайры тун кигән бер дәү абыйга карап торалар.*** **Бирелгән җөмләдән түбәндәге сүзтезмәләрне аерып чыгарырга мөмкин:**
1) ике кечкенә малай, исләре китеп, кайры тун, тун кигән, карап торалар, дәү абый;
2) ике малай, кечкенә малай, кайры тун, тун кигән, бер абый, дәү абый, исләре китеп карап торалар, абыйга карап торалар;
3) исләре китеп, ике малай, кайры тун, дәү абый, карап тора лар, ике абый, абыйга карап торалар.

**28. Татар телендә сүз төркемнәре нинди зуррак төркемчәләргә берләштереп өйрәнелә:**
1) мөстәкыйль, ярдәмлек, бәйләгеч;
2) мөстәкыйль, модаль, ярдәмлек;
3) мөстәкыйль, модаль, бәйләгеч.

**29. Синнән башка яши алмыйм (Җ.) «Башка» сүзе бу очракта:**
1) юнәлеш килешендәге исем;
2) бәйлек;

3) сыйфат.

**30. Кайсы төркемдә хәрәкәт фигыльләре бирелгән:**
1) яту, утыру, яшәү;
2) йөгерү, йөзү, әйләнү,
3) сөртү, вату, актару.

**31. *Тыпыр-тыпыр* биергә тимер идәннәр кирәк (Җ.) җөмләсендә** *тыпыр-тыпыр сүзе*:
1) рәвеш;
2) ымлык;
3) аваз ияртеме.

**32. *Кем соң ул? Җибәрәмме соң мин сине?* (Г.К.)**
**җөмләсендә** «соң» **сүзе:**
1) бәйлек;
2) рәвеш;
3) кисәкчә

**33. *Яман эшкә килер, ялкау ашка килер* (М.) җөмләсендә *эшкә, ашка* сүзләре**
1) кыек тәмамлык;
2) максат хәле;
3) урын хәле;
4) рәвеш хәле.

**34. *Авыл тавыш-тынсыз гына яктырган хәлдә, матур уйлар уйлый идек* (Ш.К.) җөмләсендә *яктырган хәлдә* сүзләре**
1) хәбәр;
2) рәвеш хәле;
3) вакыт хәле;
4) күләм хәле.

**35. Гаризасына кадәр язып керттеләр. җөмләсендә *гаризасына* кадәр сүзе**
1) туры тәмамлык;
2) кыек тәмамлык;
3) рәвеш хәле;
4) күләм хәле.

**36. *Тел әйтә алмаганны җыр әйтер* (М.) җөмләсендә *әйтә алмаганны* сүзе**
1) хәбәр;
2) туры тәмамлык;
3) кыек тәмамлык;
4) сәбәп хәле.

**37. Тыңлаучыны җәлеп итә торган кереш сүзләрне билгеләгез:**
1) кара инде, әйтсәм әйтим, гафу ит, беләсең килсә;
2) табигый, гадәттәгечә, гадәт буенча, билгеле булганча;
3) мисал өчен, ниһаять, өлешчә, иң мөһиме, әйтик, шуның белән бергә;
4) ихтимал, шәт, бәлки, күрәсең, ни өчендер;
5) әлбәттә, билгеле, чынлап та, бәхәссез, шиксез.

**38. Ике составлы җөмләне билгеләгез:**

1) Умырзая җыйдык, кошлар сайравын тыңладык, рәхәтләнеп ял иттек (Г. М.).

2) Аның күзләренә ак төшкән (М.Г.).

3) Тауга карап тау булып булмый (М.).

**39.** ***Сүзне алардан башларга кирәк булгандыр миңа*** **(Р.Төхвәтуллин) җөмләсе**

1) ким җөмлә;

2) билгеле үтәүчеле җөмлә;

3) билгесез үтәүчеле җөмлә;

4) гомуми үтәүчеле җөмлә.

**40.** ***Тимере бар тилмермәс*** **(М.) җөмләсе**

1) гади җөмлә;

2) аналитик иярченле кушма җөмлә;

3) синтетик иярченле кушма җөмлә;

4) тезмә кушма җөмлә.

**41.** ***Олылар тегермән юклыгына ризалаштылар, тик малай-шалай, егет-җилән буа юклыктан бик интекте*** **(А. Г.) җөмләсе**

1) гади җөмлә;

2) ике компоненттан;

3) өч компонетенттан;

4) дүрт компоненттан тора.

**42.** ***Бәхете юкның итәгенә бодай салсаң, түгелер (М.)*** **җөмләсе:**

1) иярчен шарт җөмлә;

2) дәрәҗәле иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

3) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

4) катнаш кушма җөмлә.

**43. Иярүче сүз ияртүчедән аңлашылган физик хәрәкәтнең максатын белдерә торган сүзтезмәне табыгыз.**

А) суга чыгу;

Ә) әбиләргә бару;

Б) сиңа бирү,

В) чүмәләгә җыю.

**44. Иярүче сүз белән ияртүче сүз арасындагы бәйләүче чараны билгеләгез.**
***Белер өчен килү***

А) янәшә тору,

Ә) бәйлек;

Б) исем фигыль формасы;

В) сүзнең лексик мәгънәсе.

**45.** ***Буяучыга да кереп чыгасым бар (К.Н.)*** **җөмләсе — ...**

А) ике составлы җөмлә;

Ә) бер составлы атау җөмлә;

Б) бер составлы фигыль җөмлә;

В) бер составлы сүз җөмлә.

**46. Рәхимовлар гаиләсе белән катышу Хәяткә *беркадәр* үзгәреш бирми кала алмады. (Ф.Ә.) җөмләсендә астына сызылган сүзнең җөмлә кисәге буларак функциясен билгеләгез.**

А) ия;
Ә) аергыч;
Б) тәмамлык;
В) хәл.

**47.** ***Түзә алмагач, барысы да җыелып баш күтәргәннәр, хуҗага каршы*** **(Х.В.) җөмләсендә астына сызган сүзләрнең җөмлә кисәге буларак функциясен билгеләгез.**
А) ярашкан аергыч;
Ә) ярашкан тәмамлык;
Б) аерымланган тәмамлык;
В) керешмә.
**48. Җөмләнең төрен билгеләгез.**
**Тау башы, пыяла вагы сибелгәндәй, ялтырап ята (Ф.Ж.)**
А) гади җөмлә;
Ә) тезмә кушма җөмлә;
Б) иярченле кушма җөмлә.

**49. Иярченле кушма җөмләдәге иярчен җөмләнең төрен билгеләгез.**
***Син аңла: мондый әсәр язарга ярамый*** **(А.Р.)**
А) синтетик иярчен ия җөмлә;
Ә) аналитик иярчен ия җөмлә;
Б) аналитик иярчен тәмамлык җөмлә;
В) синтетик иярчен тәмамлык җөмлә.

**50. Кушма җөмләнең төрен билгеләгез.**
***Күктән яумаганда үзебез су сиптерик, ансыз азык булмас, азыксыз ни сөте-мае, ни ите өстәлгә менмәс*** **(Э.К.)**
А) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
Ә) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
Б) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
В) катнаш кушма җөмлә

**51. Җөмләдәге хәбәрлекләрнең чикләре дөрес билгеләнгән вариантны күрсәтегез.**
А) (1) — Әти, (2)сиңа хәзер ризык бирерләр, (3) аннан соң бераз ял итәрсең дә без нинди хәлләр баштан узганны сөйләшербез (Ф.Ә.)
Ә) (1) - Әти, сиңа хәзер ризык бирерләр, (2) аннан соң бераз ял итәрсең дә (3) без (4) нинди хәлләр баштан узганны (3) сөйләшербез (Ф.Ә.)
Б) (1) — Әти, сиңа хәзер ризык бирерләр, (2) аннан соң бераз ял итәрсең дә (3) без нинди хәлләр баштан узганны сөйләшербез (Ф.Ә.)
В) (1) - Әти, сиңа хәзер ризык бирерләр, (2) аннан соң бераз ял итәрсең дә (3) без нинди хәлләр баштан узганны (4) сөйләшербез (Ф.Ә.)

**52. Җөмләгә кирәкле тыныш билгеләрен куегыз.**
***Чаршау булгач рәхәт ичмаса кирәкмәгәндә күтәрелеп тора кеше-фәлән килсә кирәге чыкса мич буеннан стенагача тартып куясың һәр як үзенә мич алды хатыннар ягы үзенә аерыла*** **(Г.И.)**

